# Түгәрәк уен

ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫН ЯКТЫРТУЧЫ МӘГЪЛҮМАТИ-ПОПУЛЯР АЛЬМАНАХ

3/ 2025

**«Тормыш рәвеше – Мәдәни код» фестивале – мәдәни мирасыбызны саклау, аны заманча сәнгать һәм дизайн аша яңадан аңлату мәйданчыгы**



СТИЛЬ ЖИЗНИ
КУЛЬТУРНЫЙ КОД
фестиваль


BLEUM









# Казанда – «Тормыш стиле – Мәдәни код» IV Этно-Fashion фестивале

**Казанда сентябрь башында мода һәм сәнгать дөньясындагы уникаль вакыйга – «Тормыш стиле – Мәдәни код» IV Этно-Fashion халык иҗаты һәм декоратив-гамәли сәнгать фестивале узды. Ул Россиядән һәм чит илләрдән килгән этнодизайнерларны, халык һөнәрчелеге осталарын һәм заманча медиа-сәнгать вәкилләрен бер сәхнәгә җыйды.**




Фестивальнең төп тамашасы – этник мода юнәлешендә эшләүче дизайнерларның коллекцияләрен күрсәтү иде. Бу гади дефиле генә түгел, ә чын мультимедиалы шоу булды. Милли орнаментлар, югары мода үрнәкләре һәм халык киемнәренә хас мотивлар визуаль эффектлар һәм цифрлы сәнгать ярдәмендә яңача яңгыраш тапты. Чарада үз коллекцияләрен 44 дизайнер тәкъдим итте.

Подиумда Татарстан, Башкортостан, Чувашия, Удмуртия, Мәскәү, Самара, Липецк, Красноярск, Киров, Екатеринбург шәһәрләре, шулай ук Төркия, Малайзия, Казахстан, Кыргызстан һәм Үзбәкстаннан килгән дизайнерларның коллекцияләре күрсәтелде.

«Тормыш стиле – Мәдәни код» IV Этно-Fashion фестивале кысаларында «ЭТНИКА. МОДА. ҺӨНӘРЛӘР. МӘДӘНИ КОД» темасына фидбэк-сессия дә уздырылды.

Фидбэк-сессиянең спикерлары арасында чит илдән һәм Россиянең төрле төбәкләреннән килгән дизайнерлар һәм халык сәнгате һөнәрләре традицияләрен саклаган борынгы предприятиеләр вәкилләре бар иде. Фикер




алышуда Малайзиядән килгән дизайнер, «Miami Modest Fashion Week»ка нигез салучы һәм оештыручысы, Көньяк-Көнчыгыш Азия Ислам модасы фестивален нигез салучыларның берсе һәм оештыручысы Мохд Хаири Хишам бин Мохт ашаара, иң күренекле төрек дизайнерларының берсе, үз коллекцияләрендә Госманлы империясе тарихы белән рухланып эшләнгән күлмәк фасоннарын тудыручы Рабия Ялчин, BURO BANU брендын гамәлгә куючыларның берсе һәм аның баш дизайнеры Элара Шәйхи, Татарстан модельеры Солтан Салиев, «Турина гора» халык сәнгать һөнәренә һәм шул исемдәге Барнаулдагы беренче шәхси галереяга нигез салучы Владимир Москвитин, Иваново өлкәсенең яшь рәссамы, «Холуй җөе» ҖЧҖне гамәлгә куючыларның берсе Александр Саков, киемнәрне йолдызлык билгеләренә карап эшләү һәм сайлап алу буенча уникаль концепция авторы, рәссам-модельер Елена Махиня, Чувашия Республикасының «Паха Тере» сәнгать һөнәрләре фирмасы» ҖЧҖ директоры Наталия Посынкина һәм башкалар катнашты.

«Тормыш рәвеше – Мәдәни код» фестивале – мәдәни мирасыбызны саклау, аны заманча сәнгать һәм дизайн аша яңадан аңлату мәйданчыгы. Ул талантлы дизайнерларга һәм осталарга ярдәм итү, этник эстетиканы киң җәмәгатьчелеккә җиткерү һәм халыкара мәдәни багланышларны ныгыту максатын куя.

**Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан**

# Эчтәлек

## ТАТАР ДӨНЬЯСЫНЫҢ ТРАДИЦИОН МӘДӘНИЯТЕ ЯҢАЛЫКЛАРЫ




4 **Бердәм Фольклор көне**

6 **Осталар «РОСТКИ» форумы кунакларына Татарстан һөнәрләрен күрсәтте**

9 **«Халык сәнгате һөнәрләре – илебезнең тере тарихы»**

11 **Борынгы халык уеннарында көч сынашты**


## ҺӨНӘРЛЕ УЛМӘС...




12 Г. Вәлиева-Сөләйманова **Казан һәм Казан арты – татар халкының борынгы сәнгать һөнәрләре үзәкләре**


## ӘДӘБИ МИРАС




22 Л. Мөхәммәтҗанова **«Алпамыш» дастаны турында**



**Түгәрәк уен**

№ 3 (57) / 2025


*Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул,*
*моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул.*

*Г. Тукай*


16+ Татар халык иҗатын яктыртучы мәгълүмати-популяр альманах

**Гамәлгә куючылар:**
Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге



**Редколлегия:**
Ирада Аюпова
Марсель Бакиров
Тәлгат Галиуллин
Дания Заһидуллина
Марс Тукаев
Фәрит Юсупов

**Директор:**
Алсу Равил кызы Мифтахова
**Баш мөхәррир:**
Рәзинә Әхтәм кызы Исмәгыйлева

**Альманахның иҗат төркеме:**
Гөлназ Латыйпова
Илнара Гәрәева

**Дизайнер һәм биткә салучы**:
Диләрә Нәүрузова



Альманах 2020 елның 13 ноябрендә элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр даирәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәт идарәсендә (Роскомнадзор) теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79590. Журнал өч айга бер чыга. Бәясе ирекле.

Кәгазь форматы 60×90 ⅛.
Күләме 8 басма табак.
Басарга кул куелды: 11.09.2025
Чыгу көне: 26.09.2025
Заказ: № 284. Тираж: 1000 экз.

Редакция һәм нәшер итүче:

420021, Казан, Тукай ур., 74 а.
Хатлар язар өчен адрес:
420015, Казан, Пушкин ур., 66/33
тел.: 293-27-99.
E-mail: tugarakuen@mail.ru

Отпечатано в ИП Селиванова А.Г.
420015, Казань, Галактионова, 14
тел.: +7(843)2382449
E-mail: Orange_k@list.ru



Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.
Күчереп басканда, «Түгәрәк уен» альманахына сылтама ясау мәҗбүри.


**Тышлыкта:** «Тормыш рәвеше – Мәдәни код» фестиваленнән күренешләр.


© «Түгәрәк уен», 2025

ХАЛКЫБЫЗНЫҢ КҮРКӘМ БӘЙРӘМНӘРЕ



28 **Л. Хәкимова**
**Арча читекләре**

МИФОЛОГИК МИРАС

33 Г. Гыйльманов
**Татарларның яшерен теле**

СӘХНӘ



38 Р. Мөхәммәтова
**«Былбыл» театры – чын театр»**

**Питер татарлары спектакль уйный**

БЕЗГӘ ЯЗАЛАР




46 З. Мөхәммәтшина
**«Садә»леләр тарихыннан...**

БЕЗНЕҢ КИТАПХАНӘ



50 **Камыр батыр**

БЕЗ, БЕЗ, БЕЗ ИДЕК...



54 Р. Степанова
**Кабак бәйрәме**

58 **Бибиләр**
*(җыр)*

ӨЙ КҮРКЕ – АШ



59 **Татар милли ризыклары турында табышмаклар**

60 **Вак бәлеш**

ЯЛ СӘГАТЬЛӘРЕНДӘ

62 **Бергәләп бизибез!**



# Бердәм Фольклор көне

Быелның 17 июлендә Татарстанда бишенче тапкыр «Бердәм Фольклор көне»н билгеләп үттеләр.

Әлеге бәйрәм В.Д. Поленов исемендәге Россия Дәүләт халык иҗаты йорты инициативасы белән уздырыла. Ул күп милләтле Россия халыкларының традицияләрен саклауга һәм популярлаштыруга, һәм шулай ук илебезнең матди булмаган этнокультура казанышын саклаучыларга игътибар күрсәтүгә юнәлтелгән. Бу көннәрдә бөтен ил буенча матди булмаган этнокультура казанышы объектларын презентацияләүләр, фольклор бәйрәмнәре, концертлар, мастер-класслар, традицияләрне саклаучылар белән иҗади очрашулар уздырылды. Быел әлеге чаралар ике мөһим датага: Бөек Ватан сугышында Бөек Җиңүнең 80 еллыгы һәм Поленов йортының 110 еллыгына багышланды.

«Бердәм Фольклор көне» Бөтенроссия акциясе кысаларындагы чаралар Казанда А.С. Пушкин исемендәге Мәдәният үзәгендә үтте. Биредә матди булмаган этнокультура казанышы объектының иң яхшы паспорты өчен 2025 елның 18 июненнән 17 июленә кадәр уздырылган «Милли казаныш» республика конкурсына йомгак ясадылар. Конкурсны «Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе оештырды һәм ул республикабызның матди булмаган этнокультура казанышлары объектларын ачыклау,



саклау, өйрәнү, актуальләштерү, файдалану һәм популярлаштыру максатларыннан уздырылды. Конкурста финалга чыгучыларны Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге директоры Алсу Мифтахова котлады.

Матди булмаган этнокультура казанышы объектының иң яхшы паспорты өчен «Милли казаныш» Республика конкурсында Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге учреждениеләренең үзәкләштерелгән системасына «Чыштыр» паспорты (үзенчәлекле татар-мишәр биюе) өчен I дәрәҗә диплом тапшырылды.

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының мәдәният һәм ял үзәге булган Мәләкәс авылы Мәдәният йортына керәшеннәрнең «Ышкып бию» паспорты өчен II дәрәҗә диплом тапшырылды.



Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы мәдәният йортына «Удмуртларның «Акашка» календарь-йола бәйрәме» паспорты һәм Балтач үзәкләштерелгән авыл клубы системасына «Кубыз» (удмуртларның скрипка тибындагы өч кыллы инструменты) өчен III дәрәҗә дипломнар тапшырылды.

«Бердәм Фольклор көне» Бөтенроссия акциясе кысаларында «Хоббидан бизнеска: нәрсәне белү мөһим» дигән лекция укылды, аның барышында спикер Диана Басыйрова уңышлы бренд үсеше этаплары, креатив индустрияләр өлкәсендә үз клиентыңны ничек табу мөмкинлеге, һөнәрләрне бәяләү кагыйдәләре турында сөйләде.

Бәйрәм барышында «Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары һәм хезмәт күрсәтүләр» конкурсының «Халык сәнгате һөнәрләре эшләнмәләре» номинациясендә җиңүчеләрнең күргәзмәсе дә оештырылды. Анда катнашучылар күн эше, күн мозаикасы, зәркәнчелек, агач эшкәртү, тукыма бизәү, чүлмәкчелек, укалап чигү, һәм шулай ук бизәнү әйберләре җитештерү кебек һөнәр төрләре белән таныштырдылар.

Конкурс «Россиянең 100 иң яхшы товары» программасын гамәлгә ашыру кысаларында узды. Быел әлеге конкурска Татарстан Республикасының 53 җитештерүчесеннән 140 эшләнмә тәкъдим ителде.






# Осталар «РОСТКИ» форумы кунакларына Татарстан һөнәрләрен күрсәтте




2025 елның 18-19 августында Казанда гаять мөһим халыкара чара – «РОСТКИ: Россия һәм Кытай – үзара файдалы хезмәттәшлек» III Халыкара форумы һәм Russia-China Expo күргәзмә экспозициясе булып узды. Күренекле вакыйга буларак, Форум Россия һәм Кытайның бик күп югары дәрәҗәдәге кунакларын, хөкүмәт, бизнес һәм фәнни берләшмә вәкилләрен үзенә җыйды. Ул үзара мөнәсәбәтләр үсешендә һәм яңа проектларны гамәлгә ашыруда әһәмиятле адым булачак.

18 августта Форумның тантаналы ачылышы булды. Тантанада Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Чувашия Республикасы башлыгы Олег Николаев, Оренбург



өлкәсе губернаторы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Евгений Солнцев, Кытайдагы Шаньдун провинциясенең Халык сәяси консультатив советы партиясе төркеме әгъзасы, Шаньдун провинциясенең Иҗтимагый фәннәр ассоциациясе рәисе Тан Чжоуянь, Кытай Халык Республикасының Казандагы Генераль консулы Сян Бо һәм башкалар катнашты.

Тантана Форумны ачып җибәрде һәм Россия белән Кытай арасындагы партнерлыкны ныгытуга багышланган фикер алышулар һәм чараларга юнәлеш бирде. Форумда катнашучылар хезмәттәшлек итүнең актуаль мәсьәләләре буенча фикер алыштылар, идеяләр алмаштылар һәм төрле өлкәләрдә уртак эш алып бару юлларын билгеләделәр.

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы үз юнәлеше буенча эшлекле сессия оештырды. «Матди булмаган этномәдәни казанышны өйрәнү һәм саклау буенча бөтендөнья һәм региональ тәҗрибәләр» темасына уздырылган сессиядә Мәскәү, Санкт-Петербург, Пермь, һәм шулай ук Кытай Халык Республикасы вәкилләре катнашты. Сессияне «РОСТКИ» Россия-Кытай форумы кысаларында үткәрү бөтендөнья халыкларының уникаль мәдәни ресурсларын актуальләштерүгә юнәлтелгән иде. Матди булмаган этномәдәни казанышны өйрәнү һәм саклау буенча иң яхшы тәҗрибәләр алмашу һәр ил мәдәниятен үзара баетырга, алар арасындагы үзара халыкара хезмәттәшлекне үстерергә, халыкларыбызның һәм аларның менталитетының мәдәни кодларын яхшырак аңларга ярдәм итәчәк.

«Матди булмаган этномәдәни казанышны өйрәнү һәм саклау буенча бөтендөнья һәм региональ тәҗрибәләр» сессиясе эшендә спикерлар: В.Д. Поленов исемендәге Россия Дәүләт халык иҗаты йорты директоры,





Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе, сәнгать фәннәре кандидаты, профессор, Россия Федерациясенең ЮНЕСКО эшләре буенча Комиссиясе каршындагы матди булмаган мәдәни мирасны саклау Россия комитеты рәисе Тамара Пуртова, Россия тарихчысы һәм этнографы, Россия Фәннәр академиясе профессоры, Россия Фәннәр академиясенең тарих-филология бүлеге член-корреспонденты Александр Черных, тарих фәннәре кандидаты, Россия Фәннәр академиясенең Урал бүлеге Пермь фәнни үзәгенең тарих, археология һәм этнография бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре, «Пермь этнологик тикшеренүләр һәм этномәдәни проектларны гамәлгә ашыру үзәге» ассоциациясе директоры Михаил Каменских, икътисад фәннәре кандидаты, Россия фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институтында Хәзерге Кытайны өйрәнү үзәгенең баш фәнни хезмәткәре Елена Баженова, икътисад фәннәре докторы, профессор, «Ерак Көнчыгыш проблемалары» журналының баш мөхәррир урынбасары, Россия фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институтында Хәзерге Кытайны өйрәнү үзәгенең баш фәнни хезмәткәре Андрей Островский, «Газпром-Медиа Холдинг» АҖнең халыкара юнәлеш җитәкчесе Дарья Богданова, Благовещенск Дәүләт педагогика университеты доценты Ли Тунтун, Кытай Үзәк милләтләр университетының Этнология һәм социология институты профессоры Чэнь Си катнашты.

«РОСТКИ: Россия һәм Кытай – үзара файдалы хезмәттәшлек» III Халыкара форумы кысаларында шулай ук халык сәнгате һөнәрләре осталары ярминкәсе һәм «Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан оештырылган халык һөнәрләре һәм декоратив-гамәли сәнгать буенча мастер-класслар үткәрү мәйданнары эшләде. Мастер-класслар үткәрү мәйданы «Су», «Агач», «Ут», «Металл» зоналарына бүленгән иде. Биредә кунакларга һәм чарада катнашучыларга күн мозаикасы, «Эбру» – суда буяулар белән рәсем ясау, кәгазьгә «Гжель» бизәкләрен төшерү, агач кашыклар һәм матрешкаларны бизәү техникаларын өйрәнү, татарларның борынгы милли уен кораллары – думбыра, кыл-кубызда уйнау, каллиграфия, челтәр үрү нигезләренә төшенү мөмкинлеге бирелде.

Халык сәнгате һөнәрләре осталары ярминкәсе эшендә 31 оста катнашты. Алар күн эшләнмәләр, йон промыселы продукциясе, керамик һәм көмеш эшләнмәләр, хушбуйлар, милли баш киемнәре, кулдан эшләнгән сабыннар, агачтан ясалган эшләнмәләр һәм башкаларны тәкъдим итте.



# «Халык сәнгате һөнәрләре – илебезнең тере тарихы»




4-7 август көннәрендә Казанда «Регионнарның мәдәни коды» халык сәнгате һөнәрләре казанышлары күргәзмәсе узды. Анда Россиянең төрле төбәкләреннән килгән осталарның күңел җылысын биреп, кулдан эшләнгән уникаль бизәнү әйберләре, аксессуарлар, интерьер предметлары һәм милли киемнәр белән танышырга мөмкин иде.

Күргәзмә ачылышында катнашучыларны Татарстан мәдәнияте министры урынбасары Дамир Натфуллин сәламләде. «Халык сәнгате һөнәрләре – илебезнең тере тарихы, ә осталар һәм һөнәрчеләр хезмәте – илебезнең һәм Татарстан Республикасының киләчәге һәм хәзергесе», – диде ул. Аның фикеренчә, әлеге проектның максаты – халык сәнгате һөнәрләрен алга җибәрү.

«Регионнарның мәдәни коды» халык сәнгате һөнәрләре казанышлары күргәзмәсендә халык сәнгате һөнәрләре предприятиеләре, халык осталары, Россиянең 24 регионыннан һәм Үзбәкстаннан килгән 60тан артык һөнәрче катнашты. Алар арасында Мәскәү, Санкт-Петербург, Екатеринбург шәһәрләреннән; Башкортостан, Кырым, Чувашия, Саха (Якутия) республикаларыннан; Алтай һәм Красноярск крайларыннан, Ханты-Мансийск автономияле округы – Юградан һәм Түбән Новгород, Киров, Кострома, Самара, Саратов, Иваново, Курск, Калуга, Оренбург, Пенза, Нижегородск, Липецк, Калининград, Омск, Ярославль, Мәскәү, Орлов, Ленинград, Свердловск өлкәләреннән килгән осталар бар иде.

Быел Казанга беренче мәртәбә «Вятка сувенирлары» (Киров өлкәсе), «Турина гора» (Алтай крае, Барнаул шәһәре), «Холуй җөе» (Иваново өлкәсе, Холуй авылы), «Тукылган бизәкләр» (Нижегородск өлкәсе) һәм Мамыкчылар гильдиясе (Оренбург өлкәсе) кебек федераль исемлектәге күренекле халык сәнгате һөнәрләре предприятиеләре дә килде.

Күргәзмә чатырларында кызыксынучылар өчен мавыктыргыч мастер-класслар уздырылды: «Вороновлар династиясе чигеше йорты»ның чигү ысулларын күрсәтү; атаклы Оренбург шәлен бәйләү өчен





йон хәзерләү – тәрәшләү (тарап чистарту), эрләү һәм бәйләү; пумала белән Северодвинск, Гжель, Тагил бизәкләрен төшерү ысуллары; «Студия Гуслица» матрешкасын буяу; Россиянең иң яхшы осталарыннан тукучылык дәресләре алу.

Күргәзмәне «Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге» һәм «Мирас һәм традицияләр» халык сәнгате һөнәрләре, һөнәрчеләр һәм рәссамнар оешмалары» Ассоциациясе оештырды. Чара Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының финанс ярдәме – грант нигезендә тормышка ашырылды.







# Борынгы халык уеннарында көч сынашты



7 сентябрьдә Казанның «Елмай» балалар паркында, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы ярдәмендә, «Уен фест. Ажаган» V төбәкара фестиваль-конкурсының финалы узды. Әлеге фестиваль – халкыбызның мәдәни мирасын, гореф-гадәтләрен саклап калып, яшь буынга тапшыруның күркәм үрнәге.

Быелгы фестиваль-конкурсның сайлап алу турларында республиканың төрле районнарыннан дистәләгән балалар һәм яшьләр командалары катнашты. Финалга шуларның иң көчлеләре чыкты. «Елмай» паркында үткән бәйрәмдә алар борынгы халык уеннарында көч сынашты.

«Уен фест-2025» фестиваль-конкурсында Гран-при бүләген Теләче районының «Чулпан» командасы алды. Шулай ук җиңүчеләр арасында Әтнә районының «Балкыш», Бөгелмә районының «Прогресс», Зәй районының «Кудесники книг», Ютазы районының «Рябинушка» командалары, Биектау районының «Фирүзә» җыр һәм бию ансамбле, Чүпрәле районының – «Таң», Яшел Үзәннең «Алтын» җыр һәм бию халык ансамбльләре бар.

**Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан**

# КАЗАН ҺӘМ КАЗАН АРТЫ – *татар халкының борынгы сәнгать һөнәрләре үзәкләре*

**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова,**
*сәнгать фәннәре докторы, профессор*



**Татарстанда борынгы сәнгать һөнәрләренең үзенчәлеге милли мәдәният үсеше шартлары нәтиҗәсендә барлыкка килә. Биредә Казанның татар бистәләре һәм Казан арты авылларында яшәүче татарларның тарихи территорияләре төп рольне уйный.**

XVIII гасырдан алып, Казанның Иске һәм Яңа бистәләрендә, татарлар тупланып яшәгән мәхәллә эчендә, татар милли мәдәнияте формалаша. Аның үсешендә XIX гасырның икенче яртысында – XX гасыр башында товар җитештерүнең капиталистик формалары нигезендә массакүләм үсеш алган традицион сәнгать һөнәрләре һәм кәсепләре зур роль уйный. Бу процесста Казан татарлары тупланып яшәгән борынгы район – «Казан арты» – «Ак як» аерым урын алып тора. Казан артының этномәдәни чикләре хәзерге Арча, Биектау, Саба, Теләче, Балтач районнарын, Кукмара һәм Мамадышның аерым өлешләрен, Яшел Үзән районының төньягын, шулай ук уң як Идел ярының төньяк өлешен – Тау ягын: Яшел Үзәннең көньяк-көнбатышын, Буа, Апас, Кайбыч районнарының төньягын (районнарның үзгәреп торган номенклатурасы һәм чикләре белән бәйле рәвештә аларның атамалары да үзгәреп тора) үз эченә алган.

Казан арты тарихы гасырлар тирәнлегенә барып тоташа, ул Идел буе Болгар, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы тарихы, татар мәгърифәтчелеге һәм сәнгать һөнәрләре үсеше үзәкләре булган Алат, Арча, Иске Ашыт, Җөри, Саба, Әтнә һәм башка зур җирлекләрнең үсеше белән бәйле. Бу төбәк хәзерге заман Татарстан картасында татар халкының рухи үсеше тарихын, татар мәдәниятен өйрәнү мөмкинлеген бирә. Совет тарихчылары фикеренчә, «биредә Казан ханлыгының төп территориясе була, бу җирләр Рус дәүләте составына кушылганнан соң, Казан татарларының мәдәни үзәге бирегә күчеп урнаша».



Читек тегү остасы.
Казан, XX гасыр башы

Хәзерге Казан арты Татарстан Республикасы картасында берничә административ районны берләштерә. Казанның татар бистәләренә халык нәкъ менә шул төбәкләрдән күчеп утыра, һәм Яңа һәм Иң Яңа заманда формалашкан татар мәдәнияте сәнгате традицияләренең һәм рухи кыйммәтләренең чишмә башы шуннан башлана.

Казан һәм Казан арты авылларының социаль-икътисади алгарыш процессындагы тарихи-мәдәни үсештә халык һөнәрләре һәм кәсепләренең гасырлар дәвамында формалашкан традицион җитештерү ысуллары аерым бер роль уйный. Мөселманнарның этник мәдәнияте үсешендә декоратив-гамәли сәнгать төп урынны били. Казан арты авылларында аның традицияләре Урта гасырлар чорыннан башлап сакланып килә.

XVIII-XIX гасырларда Казанда һәм Казан арты авылларында декоратив-гамәли сәнгать эшләнмәләрен күпләп җитештерү традицион һөнәрләрнең этно-мәдәни киңлеген барлыкка китерә. Әлеге процесс авыл һәм шәһәр һөнәрчеләрен үзара берләштерә, һәм бу шәһәр югарылыгындагы сәнгать һөнәрләренең һәм авыллардагы халык сәнгате традицияләренең бердәм үсеше өчен уңайлы нигез булып тора.

Аеруча XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башында әлеге сәнгатьнең төрләре һәм технологияләре авыл шартларында да, шәһәрләрдә дә һөнәрчелек һәм аны үстерү формалары үсешендә төп роль уйный.

Шәһәр һәм авыл һөнәрчеләре арасындагы икътисади хезмәттәшлек якынча XIX гасыр урталарыннан башлана. Шулай да бу өлкәдәге сәнгатьчә технология ысуллары Казан арты авылларында тупланган була.

Ә Казан яулап алынганнан соң якынча йөз ел үткәч һәм феодаль түрәләр – татар морзалары юкка чыккач, шәһәр татарлары

*МӨСЕЛМАННАРНЫҢ ЭТНИК МӘДӘНИЯТЕ ҮСЕШЕНДӘ ДЕКОРАТИВ-ГАМӘЛИ СӘНГАТЬ ТӨП УРЫННЫ БИЛИ. КАЗАН АРТЫ АВЫЛЛАРЫНДА АНЫҢ ТРАДИЦИЯЛӘРЕ УРТА ГАСЫРЛАР ЧОРЫННАН БАШЛАП САКЛАНЫП КИЛӘ.*



һөнәрчелегенең үсеше туктала. Алга таба бу һөнәрчелекнең авыл чынбарлыгына хас булган хуҗалык һәм икътисад шартларында дәвам итүенә китерә. Казан артындагы күп кенә авыллар ярым шәһәр тибындагы зур торулыклар булып китә, биредә крестьяннарның халык сәнгате һәм шәһәрдән кысрыклап чыгарылган сәнгать һөнәре бербөтен система хасил итә.

Казан артында шәһәрдән качып киткән татар халкы туплана. Бу элеккеге шәһәр мәдәнияте элементларын, аерым алганда, тарихи һәм типик яктан шәһәр һөнәрчелегенә хас булган сәнгать һөнәрләре төрләренең киң таралуына ярдәм итә. Боларга күн эше (бизәкле басма һәм каюлы күн технологияләре), металлны сәнгатьчә эшкәртү (кою, басма, чүкү, төймә техникалары), зәргәрчелек (җепкыр, төймә, уеп кисү техникалары), укалап чигү, кабер ташларына уеп бизәк төшерү, хаттатчылык (каллиграфия) сәнгатьләре керә.

Декоратив-гамәли сәнгатьнең традицион үрнәкләрен, һөнәр төрләрен һәм технологияләрен өйрәнү – Казан арты татар авылларындагы сәнгать үсешенең югары формалары турында сөйли. Профессиональ һөнәрчеләрнең шактый зур тупланышы Казан артын «авыл тормышы шартларында шәһәр мәдәниятенә хас декоратив-гамәли сәнгать төрләре үсешенә ия булган территория» дип атарга мөмкинлек бирә. Бу Урта гасырларда Казан арты авыллары шәһәр тибындагы үзәкләр булганлыгы турында сөйли. Алар исә Казан арты авылларында шәһәр кешеләре һөнәре һәм крестьян тормышы белән бәйле халык иҗаты традицияләренең үсеше нигезендә формалашкан профессиональ сәнгать барлыкка килүгә ярдәм итә.

XVIII гасыр уртасыннан XIX гасыр уртасына кадәр Казан артында, шулай ук Казанның Иске һәм Яңа татар бистәләрендә бизәкле аяк киемнәре, укалы баш киемнәре һәм йола сөлгеләре, йонсыз тукылган келәмнәр, металлдан эшләнгән көнкүреш һәм зәргәр бизәнү әйберләре, шамаилләр һәм башка йорт кирәк-яраклары җитештерүче осталар эшли. Сакланып калган эшләнмә үрнәкләре буенча шәһәр һәм авыл



**Комган һәм ләгән. Чүкеп бизәк ясау, XIX гасыр**

осталары җитештергән әйберләрнең сәнгать үзенчәлекләрен аерып күрсәтергә була. Шәһәр һөнәрчеләре бары тик заказ буенча һәм нигездә халыкның хәлле катлавы өчен эшли. Зур профессиональлеккә омтылу нәтиҗәсендә башкару техникасында да, бизәү ысуллары өлкәсендә дә югары сәнгать үрнәкләре барлыкка килә. Шәһәрнекеләр кебек үк, традиция кысаларында эшләүче авыл осталары технология һәм сәнгатьчә композиция мөмкинлекләрен сайлаганда кырыс кануннарга буйсынмыйча, ирекләрәк, индивидуальрәк эшлиләр, яисә, киресенчә, шәһәр үрнәкләренә ияреп иҗат итәләр. Бу



**Мәрҗани мәчетенең Таҗлы шамаиле.**
**Каллиграф Мотаһир Яхья. Пыяла, май, XX гасыр башы**



Энҗе белән чиккән калфакларның маңгайлыклары



Бәхет кошы калфагы. Укалап чигү. XX гасыр башы

*XVIII гасыр уртасыннан XIX гасыр уртасына кадәр Казан артында, шулай ук Казанның иске һәм яңа татар бистәләрендә бизәкле аяк киемнәре, укалы баш киемнәре һәм йола сөлгеләре, йонсыз тукылган келәмнәр, металлдан эшләнгән көнкүреш һәм зәргәр бизәну әйберләре, шамаилләр һәм башка йорт кирәк-яраклары җитештерүче осталар эшли.*

факторлар эшләнмәләрнең сәнгать сыйфаты түбәнәюенә, җитештерү технологиясенең гадиләшүенә китерә, төрле өлкәдә эшләүче осталар арасында иҗади хезмәт бүленешен китереп чыгара. Казан осталары эшләнмәләре шәһәр



Ирләр кәләпүше. XIX гасыр ахыры

мәдәниятенә хас гомуммилли сыйфатларга ия булса, авыл осталары эшләнмәләрендә җирле үзенчәлекләрне аерып карарга мөмкин. Моннан тыш, читек-кәләпүш җитештерү процессының аерым өлешләре шәһәр һәм авыл осталары арасында бүленә. Бу хакта минем «Шәһәр һәм кәсепләр: Казанда очрашу» күргәзмәсе өчен чыгарылган альбом-каталогымның аерым бүлекләрендә һәм Казан артының сәнгать һөнәрләренә багышланган махсус хезмәтемдә җентекләбрәк танышырга мөмкин [1].

[1] Традиционные художественные ремесла и промыслы Заказанья: прошлое и настоящее. – Казань: Заман. 2023. – 160 с.; Г.Ф. Валеева-Сулейманова. Связующая нить традиции. Татарские народные художественные промыслы // Ичиг, калфак, шамаиль. Традиционное искусство поволжских татар. – М.: Царицыно музей-заповедник, 2025. – С. 18-103.



Сәнгать һөнәрләре эшләнмәләрен җитештерү һәм алар белән сәүдә итү акрынлап Казанга күчә бара. XX гасыр башында ул татарлар яшәгән территориядә хезмәт бүленешенә ия булган эшләнмәләрне кулдан җитештерүгә нигезләнгән мануфактура производствосы үсешенең зур үзәгенә әйләнә. Кул һөнәре буларак билгеле булган, соңрак халык сәнгате һөнәре дип аталган мондый производство өйдә эшләүне күздә тоткан гади авыл һөнәрчелеге нигезендә барлыкка килә һәм эшләнмәләрне күпләп җитештерүгә һәм сатуга этәргеч бирә. Ул татар сәүдәгәрләре һәм шәхси эшмәкәрләр кулында туплана. Татар һөнәрчеләре эшләнмәләре Идел буе төбәгеннән шактый читтә дә тарала, Урта Азия, Казахстан һәм Көнбатыш Себергә, Россиянең татарлар яшәгән башка төбәкләренә кадәр барып җитә. Бу татарларда гомуммилли мәдәнияте формаларына китерә, бирелә исә кулдан күпләп җитештерелүче, татарларның көнкүрешен һәм кием-салымын билгеләүче эшләнмәләр зур роль уйный.

Сәнгать эшчәнлегенең Казан артында үсеш алган кайсы төрләре гомуммилли булып киткән соң? Беренчедән, милли кием белән тыгыз бәйләнгән һәм аның бизәлешенә керә торган төрләре. Казан арты уникаль каюлы күн ысулы кулланып эшләнгән бизәкле күн аяк киемнәре җитештерү үзәге була. Каюлы күн белән чигелгән бизәкле читекләр, башмаклар, чүәкләр киң тарала һәм барлык татар, башкорт һәм казахлардагы этник төркемнәрнең милли аяк киеме булып китә. XVIII гасыр азагына кадәр каюлы күн һөнәрчелеге Арча, Дөбъяз, Олы һәм Кече Кавал, Мәмдәл, Мүлмә, Урта Аты, Әтнә, Субаш, Өнсә, Урта Сәрдә, Тимерче, Ямаширмә, Кылачы, Битаман кебек авылларда өй шартларында тегелә торган бизәкле аяк киеме буларак үсеш ала. Соңрак һөнәрчелек производствосы барлыкка килә. 1840нчы елларда, вак



*КАЗАН АРТЫ УНИКАЛЬ КАЮЛЫ КҮН ЫСУЛЫ КУЛЛАНЫП ЭШЛӘНГӘН БИЗӘКЛЕ КҮН АЯК КИЕМНӘРЕ ҖИТЕШТЕРҮ ҮЗӘГЕ БУЛА. КАЮЛЫ КҮН БЕЛӘН ЧИГЕЛГӘН БИЗӘКЛЕ ЧИТЕКЛӘР, БАШМАКЛАР, ЧҮӘКЛӘР КИҢ ТАРАЛА ҺӘМ БАРЛЫК ТАТАР, БАШКОРТ ҺӘМ КАЗАХЛАРДАГЫ ЭТНИК ТӨРКЕМНӘРНЕҢ МИЛЛИ АЯК КИЕМЕ БУЛЫП КИТӘ.*



**Хатын-кызлар читеге. XIX гасыр уртасы**



**Гаилә читекләре. XX гасырның беренче яртысы**



Саба районының Йосыф Алан авылы зәргәрчесе. 1980нче еллар. Автор фоторәсеме

остаханәләр белән беррәттән, Казанда ике зур мануфактура эшли башлый, анда читтән торып эшләүче авыл осталарының хезмәте файдаланыла. Каюлы күн техникасыннан тыш, укалап алтын һәм көмеш җепләр белән чигелгән бизәкле аяк киемнәре җитештерелә башлый.

Милли киемнең бер өлеше булган зәргәр бизәнү әйберләре дә Казан арты авылларында ясала. Биредә башка халыкларның традицион сәнгатендә очрамый торган җепкыр һәм күпертмәле җепкыр ысуллары кулланыла. Нәкъ менә Казан арты татарларның барлык этник төркемнәрендә популяр булган чулпылар, алкалар, беләзекләр, хәситәләр, изүләр, каптырмалар җитештерү үзәге булып китә. Байлар Сабасы, Мөндеш, Арча, Әтнә һәм алар янәшәсендәге күп кенә авыллар зәргәрчелек һөнәре белән дан казана. Кайбер авыллар (Тенәки, Мөндеш, Йосыф Алан), билгеле бер бизәнү әйберләре (беләзекләр, чулпылар, алкалар, йөзекләр) буенча специальләшә. Бу кайбер авыл исемнәрендә дә чагылыш таба (мәсәлән, Чулпычы, Бакырчы һәм башкалар). Казанда бизәнү



Беләзек. Уеплау, асылташлар. XIX гасыр уртасы

әйберләре шәхси остаханәләрдә заказ буенча күпертмәле җепкыр кулланып җитештерелә.

Югары профессиональ сәнгать төре – укалап чигү Казан арты халык иҗатындагы шәһәр мәдәнияте традицияләре турында сөйли. Ул авыл шартларында үсеш ала һәм, каюлы күн кебек үк, халык сәнгате һөнәре формасында яшәвен дәвам итә. Башта укалап чигү шәһәр



Сөлге башы. Асалап сугу техникасы, XIX гасыр



Сөлге. Шомартып чигү, XIX гасыр

һөнәре төре буларак үсеш ала, эшләнмәләргә хан сарае вәкилләре һәм түрәләр заказ бирә. Шәһәр мәдәнияте җимерелгәннән соң, бу һөнәр авылларга күчә һәм авыл чигүчеләре иҗатында сакланып кала. XIX гасырда укалап чигү белән баш киемнәрен (түбәтәй, калфак, такыя), аяк киемнәрен (хатын-кызларның бәрхет башмаклары), изү, камзул, күлмәкләрнең аерым детальләрен бизиләр.

Казан артында торак йорт интерьерларының бизәлеше (йола «Казан сөлгеләре», чаршаулар, намазлыклар һәм башкалар) белән бәйле халык сәнгать төрләре, шулай ук җиз комганнар, ләгәннәр, көнкүреш кирәк-яраклары татарларның гомуммилли әйберләре буларак үсеш ала. Әлеге күренешне уеп таш кисү сәнгатендә (кабер ташлары) һәм агачтан уеп ясалган төсле бизәкләрдә (йортлар бизәү сәнгате) һәм



Казан сөлгесе. XIX гасыр



*КАЗАН АРТЫНДА ТОРАК ЙОРТ ИНТЕРЬЕРЛАРЫНЫҢ БИЗӘЛЕШЕ (ЙОЛА «КАЗАН СӨЛГЕЛӘРЕ», ЧАРШАУЛАР, НАМАЗЛЫКЛАР ҺӘМ БАШКАЛАР) БЕЛӘН БӘЙЛЕ ХАЛЫК СӘНГАТЬ ТӨРЛӘРЕ, ШУЛАЙ УК ҖИЗ КОМГАННАР, ЛӘГӘННӘР, КӨНКҮРЕШ КИРӘК-ЯРАКЛАРЫ ТАТАРЛАРНЫҢ ГОМУММИЛЛИ ӘЙБЕРЛӘРЕ БУЛАРАК ҮСЕШ АЛА.*

шамаил нигезендә үсеш алган басма шамаил сәнгатьтә дә күзәтергә мөмкин.

Традицион сәнгатьнең казан татарларында сәнгать һөнәрләре һәм кәсепләре формасында массакүләм үсеш алган аерым төрләре гомуммилли әһәмияткә ия булды. Иң әүвәл алар татарларның традицион сәнгать үзәкләрендә – Казан арты авылларында барлыкка килсә, соңрак Казанның һәм башка Россия шәһәрләренең татар бистәләренә дә үтеп керде.

Шулай итеп, Казан арты авыллары тарихның аерым бер чорында татар халык традицияләрен, милли һәм гомуммилли мәдәниятне саклау һәм үстерү урыны булды. Соңрак ул Казанның мәдәни провинциясе булып китте, анда исә халык сәнгате шәһәр һәм авыл традицияләре белән бергә үрелеп үсте.

**Фоторәсемнәр авторның шәхси архивыннан**



**Түбә кыегы куышы. Олы Әтнә авылы, 1960нчы еллар**

# «АЛПАМЫШ» дастаны турында

**Лилия Мөхәммәтҗанова,**
*филология фәннәре докторы, доцент,
Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов
исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать
институтының баш фәнни хезмәткәре*



## «ТОРГЫН, ЕГЕТ, ӘЙ!..»

Татарлар яши торган төбәкләрдә «Алпамыш» дастаны әле дә яши. Аның сюжетын өйрәнүче фольклорчылар чагыштырмача еш очрый. Әйтик, 2002 елгы экспедициядә язып алынган «Алыпмәмшән җыры»ннан өзек (информант – Хәлим Харисович Сәгыйдуллин (1949 елгы), Түмән өлкәсе Вагай районы Казанлы авылы) – «Алпамыш» дастаны белән турыдан-туры бәйләнешле иҗат. Информант хәтерендә калган өлешне әйтеп бирер алдыннан дастанга карата түбәндәге аңлатманы бирде: «Алыплар булган бит. Батыр кешеләр. Зур гәүдәле. Алыпмәмшәннәр. Алар турында сөйлиләр иде элек. Зинданда яткан дип. Аннан хатыны эзли чыгып киткән, коткарган. Шул турыда бу»:

*Буй гынаңа, әй,*
*Карап исәм, әй,*
*Әткәм Айтүбәгә*
*Охшатам ук, әй.*
*Торгын, егет, әй,*
*Торгын, егет, әй!*
*Әгәр тормасаң,*
*Үлдең, егет, әй!*
*Йөз гененә, әй,*
*Карап исәм, әй,*
*Әнкәм Көнәрсылуга*
*Охшатам ук, әй!*
*Торгын, егет, әй,*
*Торгын, егет, әй!*
*Әгәр тормасаң,*
*Үлдең, егет, әй!*

*(Материал Л.Х. Мөхәммәтҗанованың шәхси архивыннан.)*

Әлеге фольклор үрнәге дастанның 1971 елда Түмән өлкәсе Тубыл районы Күкрәнде авылында Шәрифҗамал Халитовадан Флора Әхмәтова язып алган вариантында китерелгән җыр текстын, кайбер морфологик-синтаксик аермаларны исәпкә алмаганда, сүзгә-сүз диярлек кабатлавы белән кыйммәт. Бу факт борынгы «Алпамыш» дастанының татарларда соңгы чорларда да исәнлеген дәлилли. Бу үрнәктә төрки героик эпосының урта гасырлардан ук килә торган мотивлары – каһарманның читкә китүе, аңа ярдәмгә килүче хатын-кыз, каһарманны танып алу һәм башкалар чалымлана. Биредә шулай ук «Алпамыш»ның күләмле версия-вариантлары аша билгеле Айтүбә, Көнәрсылу исемнәре телгә алына.

## «АЛПАМЫШ» – ТӨРКИЛӘР ФОЛЬКЛОРЫНЫҢ КЫЙММӘТЛЕ МИРАСЫ

Алпамыш турындагы эпос – дөнья фольклорында иң атаклы әсәрләрдән. Аның сюжеты казакъ, үзбәк, каракалпак, азәрбайҗан, татар, башкорт, алтай, төрек һәм таҗикларда таралыш алган, аларда күпләгән вариантларда зур популярлык казанган. Дастан әүвәл патриархаль ыру-кабилә мөнәсәбәтләре шартларында яшәгән дала күчмәләрендә барлыкка килгән дип санала. Берничә халыкта мәгълүм әлеге фольклор истәлекләре бик борынгы замannардан килә торган уртак героик «көнчыгыш» сюжетка нигезләнгән.

Төрки халыкларның кыйммәтле рухи мирасы буларак, бүген «Алпамыш» эпосын саклау буенча зур эш алып барыла: кайбер төрки халыклар аңа багышлап халыкара конференцияләр оештыра, дастан текстлары башка телләргә тәрҗемә ителә, халыкара экспертлар дастанны эпос номинациясендә ЮНЕСКОның матди булмаган мәдәни мирасы исемлегенә кертү мәсьәләсен тикшерә.

Татар версиясенең «Алыпмәмшән хикәяте», «Алыпмәмшән җыры», «Алпамша» һәм башка исемнәр белән теркәлгән вариантларының һәркайсы – урта гасыр героик «Алпамыш» эпосы белән аваздаш, төрки эпик һәм Көнчыгыш романтизмы кануннарына туры килә торган фольклор истәлекләре. Алар арасында зур күләмле текстлар да, фабула характерындагылар да, кыска сюжетлы хикәятләр, шулай ук дастан җырлары да бар. «Алпамыш»ның телдән тапшырылган төрен карыйбыз. Соңгы егерме-егерме биш ел эчендә табылган материаллар, чичән-информантлар башкаруында язып алынган булсалар да, поэтик җәһәттән борынгырак чорлардагы, һәркайсының көйле-музыкаль формасы булган күләмле ядкярләрдән гыйбарәт тулы версия-вариантлардан, әлбәттә, күпкә кайтыш. Моның сәбәпләрен чичән тарафыннан барлыкка китерелгән силлабик шигъри формалы эпосны көйләп декламацияләү традициясенең инде сүрелгәнлеге белән аңлатырга мөмкин. Шулай булса да әле чичәннәр иҗаты бөтенләй сүрелеп беткән дия алмыйбыз, табылган мисалларга карагандa, ул исән. Бу исә фольклор белән язма мәдәният арасындагы процессның өзлексез дәвам итүен, һаман үсеш-үзгәрештә булуын күрсәтә.

**Татар җырларында халкыбызның көнел түрендә йөри торган уй-теләкләре, борчу-мәшәкатьләре чагылыш тапкан, әлеге закончалык сугыш чоры лирик иҗатына да кагыла. Тормыш шартлары никадәр генә авыр булуга карамастан, халык җырлары яшәвен дәвам иткән, халыкның күңелен юаткан, кешеләрне бирешмәскә өндәгән.**

## ЭПОСНЫҢ ТАТАР ВЕРСИЯСЕ НИДӘН ГЫЙБАРӘТ?

Эпосның татар вариантлары саны дистәдән артып китә. Татарларның географик яктан таркау урнашканлыгы, халыкның төрле җирләрдә тупланып яшәүче төркемнәрендә, эпик-мәдәни традицияләрнең үзенчәлекле формалашуына һәм үсешенә китергән. Бу күп гасырлык процесс «Алпамыш» эпосы үсеше мисалында ачык күзәтелә.

Татар версиясе Идел буе һәм Себер территорияләрендә таралган текстлардан гыйбарәт. Себер татарлары вариантлары – кайчандыр чичәннәр сөйләгәннән язып алынган героик характердагы аутентик әсәрләр, «тере» фольклор үрнәкләре. Ә Идел буенда әлеге сюжетка корылган ядкярләрнең зур бер өлеше героик эпос белән «батырлык әкияте» дип билгеләнә торган жанр чикләрендә тора, ягъни әкиятләшкәннәр. Янә бер өлеш дастаннар татар эпосының китабилашу процессын кичергәннәр, бу төркем «Алпамыш» иске кулъязмалар буларак билгеле, ягъни китаби-язма дастанга әверелгәннәр. Болардан тыш, бүгенге көндә татарлар яшәгән төбәкләрдә «Алпамыш» сюжетына бәйле дастан җырлары очрап куя, болар – әле

**Төрки халыкларның кыйммәтле рухи мирасы буларак, бүген «Алпамыш» эпосын саклау буенча зур эш алып барыла: кайбер төрки халыклар аңа багышлап халыкара конференцияләр оештыра, дастан текстлары башка телләргә тәрҗемә ителә, халыкара экспертлар дастанны эпос номинациясендә ЮНЕСКОның матди булмаган мәдәни мирасы исемлегенә кертү мәсьәләсен тикшерә.**

дә шактый актив «тере» жанр, мондый иҗатка Идел буенда да, Себердә дә юлыгырга мөмкин. Дастан җырлары телдән башкарыла торган «Алпамыш»ның татарларда әле дә онытылып бетмәгәнлеген дәлилли.

Димәк, «Алпамыш» татар халкында борынгырак чорларда озын-озак итеп телдән башкарыла торган көйле дастан булган. Тора-бара дастанны әкият итеп сөйли башлаганнар. Тарихның билгеле бер чорында бу сюжет язуга күчеп, китабилашкан. Төрле территориядә таралып яшәгән һәм яшәүче татар халкының «Алпамыш» сюжетына корылган һәм алып кешеләр эпосы сыйфатларын чагылдырган фольклор әсәрләре җыелмасы барысы бергә татар «Алпамыш»ын, ягъни дастанның татар версиясен тәшкил итә.

## ТАТАРЛАРНЫҢ СЕБЕР «АЛПАМЫШ»Ы

Таралып урнашкан халыкларның берсе буларак танылган татарлар Россия Федерациясенең төрле төбәкләрендә тупланып яшиләр. Омск, Томск, Төмән, Тубыл, Новосибирск, Кемерово кебек өлкәләр – татарларның себердәге тарихи ватаны. Бу җирләрдә яшәүче информантлар халкыбызның эпик фондын беренчел вербаль эпик текстларга шактый баеткан. Себердә яшәүче татарларның эпосы нигездә телдән башкарудан язып алынган синкретик иҗат. Татар халкында «Алпамыш»ның себердә чичәннәр авызыннан язып алынган текстлары бар.

Биредә, XIX-XX гасыр башында ук, Ямәшкә карт, Рамазан Ильясов, Ситдыйк Зәйнетдинов һәм башкалар кебек мәшһүр чичәннәр булган, алар телдән эпос әйтү сәләте белән дан тоткан. «Алпамыш» кына түгел, «Мешәк алып», «Йәстәй Мөңке», «Кадыш-мәргән», «Кара Күкел», «Йиртөшлек», «Ак Күбәк», «Кузы-Күрпәч» һәм «Идегәй»нең берничә дистә варианты да нәкъ менә Себер территориясендә яшәүче информантлардан язып алынганлыгы мәгълүм. Чичән башкаруында билгеле «Алпамыш»ның да иң зур күпчелеген себер территориясе информантлары биргән. «Татар халык иҗаты» академик басмасының 1984 елда дөнья күргән «Дастаннар», 2019 елда рус телендә чыккан «Дастаны» академик томнарында 1971 елда Ф.В. Әхмәтова тарафыннан Төмән өлкәсенең Тубыл районы Күкрәнде (Чебурга) авылында (хәзер Тубыл районының Кутарбит авыл җирлеге составына керә) информант – Кави Ибраһимовтан (1912 елгы) язып алынган варианты басылып чыкты.

Себердә яшәүче татарлар тарафыннан Алыпмәмшән, Алтмамшан, Алпамша, Алпамыш, Атмамшан, Атмәмшән кебек исемнәр белән сөйләнелә торган яисә элеккерәк чорларда сөйләнелгән хикәятләр күләмле архаик «Алпамыш» эпосының сюжеты һәм мотивлары белән тирән аваздаш. Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге фондларында Төмән өлкәсе Тубыл районы Күкрәнде (Чебурга) авылында Р. Ильясов (1956 елгы) һәм З. Ильясовалардан (1956 елгы) 1971 елда Флора Әхмәтова язып алган варианты теркәлгән. Текстта «Алпамыш» дастанының күпчелек версияләре китерелгән һәм шулай ук төрки халыкларның башка героик дастаннарына хас мотивлар бар. Мәсәлән, Алыпмәмшәннең читкә чыгып китүе; аның читтә маҗараларга таруы, зинданга ябылуы; читтә йөргән Алыпмәмшән кайтып кергәннән соң, сукыр әнисенең күкрәгенә сөт төшү; шул сөт белән күзен сөртүгә аның күрә башлавы һәм башкалар.

1972 елда Төмән өлкәсенең Вагай районы Юрмы авылында 1886 елгы Аймәдетдин

Ниязовтан Флора Әхмәтова язып алган вариант шулай ук кызыклы. Биредә Карлыгачсылу Алыпмәмшәннең сеңлесе дә, хатыны да түгел, ә апасы буларак бирелгән; Алыпны зинданнан коткару мотивы бу вариантта юк, әмма ул контексттан аңлашыла; батыр каты йокыга тала, йокысыннан аны улы уята һәм башкалар.

Себерне тарихи ватаннары итеп яшәүче татарлар күчмә тормыш шартларында озаграк яшәгән. Шуңа күрә игенчелеккә, шәһәр мәдәнияте һәм язма әдәбиятка ихтыяҗ аларда чагыштырмача соң барлыкка килгән, ислам тәэсирен дә соңрак кичергәннәр. Болар барысы да эпик мәдәнияткә йогынты ясаган. Шулай ук үзәктән ераклык та себер территориясендә «Алпамыш»ның традицион телдән башкарыла торган төре яхшырак саклануын тәэмин иткән. Себердә яшәүче милләттәшләребездә дастан жанрының традицион формасына бирелә килгән өстенлек бу территорияләрдә яшәүче күрше алтай, шор, саха-якут, тува, хакас, бурят, эвенк, казакъларның, кыргызларның һәм башка халыкларның эпик культуралары тәэсире дә булырга мөмкин.



**Информант белән «Алпамыш» дастаны турында әңгәмә. Азнакай, 2019 ел**

## ИДЕЛ БУЕ «АЛПАМЫШ»Ы

Идел буенда яшәүче татарларда «Алпамыш» язмага күчеп, китабилашкан яисә, дастан жанры кысасыннан чыгып, әкиятләшкән. Алар – эчтәлеге буенча баһадир әкияте жанрына якын торган текстлар. «Алпамыш» дастанының кунграт, угыз, кыпчак, алтай версияләрен, шулай ук Урта Азия эпосында чагылышын җентекләп өйрәнгән В.М. Жирмунский Казан татарлары вариантына карата «халык әкияте» терминын куллана. Чыннан да, Татарстан территориясендә (Бондюг районы Камай авылында) Х. Ярми язып алган текстта, мәсәлән, борынгы эпик мотивларның булуы әсәрне төрки эпоска якынайтса да, ул әкият жанрына күбрәк тартыла. Моннан тыш, Татарстан территориясендә табылган ике вариант та һәм Оренбург өлкәсендә язылган тагын бер вариант шулай ук әкият жанрына карый, алар хәтта татар халык иҗаты академик басмасының «Әкиятләр» томына кертелгән (томны төзүчеләр, искәрмәләрне әзерләүчеләр – Гатина Х.Х., Ярми Х.Х., 1977).

Әкиятләшеп, телдән сөйләнгән вариантларыннан тыш, Казан татарларына «Алпамыш»ның кульязма вариантлары да билгеле. XX гасыр башында Казанда күп тапкырлар шактый күләмле «Кыйссаи Алпамыш» әсәре басылып чыккан. Димәк, гарәп язулы бу китапларга ихтыяҗ зур булган. Казанда басма китаплар чыкканчы «Алпамыш» сюжетлы текстларның күчереп язылганлыгы мәгълүм. Мәсәлән, Казан (Идел буе) федераль университетының Н. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәдә саклана торган кульязма (Алпамша хикәяте // КФУ Н. Лобачевский ис. Фәнни китапханәнең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге. Шифр: 1006 Т) – Татарстанның Минзәлә районында табылган, Габдулла Сайманов төзегән текст. 2004 елда бу вариант «Алпамша хикәяте» исеме белән «Татар эпосы. Дастаннар» китабында дөнья күргән (китапның

**Идел буенда яшәүче татарларда «Алпамыш» язмага күчеп, китабилашкан яисә, дастан жанры кысасыннан чыгып, әкиятләшкән. Алар – эчтәлеге буенча баһадир әкияте жанрына якын торган текстлар.**

төзүчесе, кереш сүз һәм искәрмәләр авторы, сүзлек әзерләүче – Ф.В. Әхмәтова-Урманче. – Казан, 2004). «Алпамыш»ның Идел буе татарларына хас кульъязма һәм басма текстларына да бер жанрдан икенчесенә күчү хас, алар, XX йөз урталарында язып алынган сөйләмә вариантлары кебек, героик әкияткә әверелүгә таба үзгәреш кичереп, трансформацияләнгәннәр.

## БҮГЕНГЕ «АЛПАМЫШ»

Соңгы елларда (2000-2025) Татарстан Фәннәр академиясенең ТӘһСИ уздырган экспедиция нәтиҗәләренә нигезләнеп, шуны әйтү мөһим: Саз ягы, Тара, Бараба авыллары татарларында әле дә алып, Мәргән һәм батырларга багышланган күпсанлы хикәятләрдән һәм дастаннан өзекләр саклана. Аларда оча торган чаңгылар киеп ерак араларны тиз генә үтә алучылар, ерактан төз атучылар, дошман алыпларын җиңүчеләр, ау вакытында урманда төрле мифик җан ияләре белән очрашып, алар белән көрәшүчеләр һәм башкалар турында сөйләнелә.

2000 елда Татарстан Фәннәр Академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Төмән өлкәсенә оештырган фольклор экспедициясе вакытында биредәге татар авылларында «Катерпәт сазлыгы турында хикәят», «Ешка өйләнгән мәргән», «Нугай алтыны һәм Котык кабиләсе турында хикәят», «Бохара шәехләре һәм изге астана» кебек эпик авыз иҗаты әсәрләре язып алынган иде (бу турыда тулырак: Мөхәммәтҗанова Л.Х. Себердә татар фольклоры // Фәнни Татарстан. – 2020. – № 4. – Б. 96-104). Боларны «Алпамыш» дастанының кайтавазы дип карарга мөмкин. Алар борынгы «Алпамыш» дастанына хас сюжет элементларын югалтканнар, әмма каһарманлык рухы, алыптай батырның яисә мәргәннең гадәттән тыш маҗаралары тасвирланган булу хикәятләренең «Алпамыш» эпосына мөнәсәбәте барлыгын раслый. Болардан тыш, Төмән өлкәсендә «Алпамыш» дастаны сюжетына турыдан-туры катнашы булган кыска хикәятләр дә язып алдык. «Алыпмәмшән хикәяте», «Алыпмәмшән кыйссасы» дип исемләнгән бу үрнәкләрдә Алпамыш (Алыпмәмшән, Алпанша һәм башкалар) исемле геройның маҗаралары турында сөйләнә.

2019 елда Татарстан Республикасының Азнакай районында фәнни экспедиция вакытында язып алынган кыска эпик җыр аеруча әһәмияткә лаек. Дастан җыры «Мәрҗәнсылуым» дип атала. Ирекле авылы информанты Савилә Юныс кызы Әхмәтшина (1937 елгы), дастаннан бер куплетны башкарып, җырның икенче исемен дә әйтеп бирде: *«Алпамыш җыры» диләр иде бу җырны:*

*Лап-лоп баскандай аюмы идең-әй?*
*Шул зинданнарга килгәнме идең-әй?*
*Мәрҗәнсылуым, Мәрҗәнсылуым,*
*Ай-һай көннәр-әй,*
*Үтте төннәр-әй»*
*(Текст фольклорчы Л.Х. Мөхәммәтҗанованың шәхси архивыннан).*

Дастан җырлары – татарларда мәгълүм күләмле эпос-дастаннардан этәрелеп, бүгенге көндә мөстәкыйльлеккә дәгъва итә торган жанр. Гадәттә, дастан җырын башкаручы информант әсәр хакында үзе үк мәгълүмат бирә, җырның тарихын әйтеп китә. Бу очракта Ирекле информанты, «Алпамыш»тан тезмә текстны көйләп күрсәткәннән соң, дастанның кыска сюжетын да сөйләде:

*«Борын заманда Алпамыш булган. Зур гәүдәле пәһлеван икән. Атасы хан, анасы ханбикә булган. Хатынының исеме – Мәрҗәнсылу. Алпамыш читкә киткән сугышка. Анда дошманнарының кулына эләккән. Зинданда ята. Еллар буе ята. Хатыны Мәрҗәнсылу*

*ирен эзләп китә. Күрә иренең зинданда ятуын. Коткара алмый, кайтып китә. Җир патшасының кызы Алпамышны коткара, аңа зинданнан чыгарга ярдәм итә. Алпамыш чыга зинданнан, аны Акбүз аты көтеп тора, Алпамыш атына атлана. Кайта үз авылына. Аны танымый торалар. Думбыра чиртеп җыр әйткәннән соң Мәрҗәнсылу Алпамышны таный. Мәрҗәнсылуның түе икән. Мәрҗәнсылу ирен таныды бит инде. Ук аттырып карый. Алпамыштан да тизрәк ата алмый беркем. Алпамыш җиңә. Мәрҗәнсылу белән кабат никахлана Алпамыш».* (Текст фольклорчы Л.Х. Мөхәмmәтҗанованың шәхси архивыннан).

Шул рәвешле, Татарстан территориясендә XXI гасыр башы информанты «Алпамыш» дастанының бик кыска гына шигъри өлешен көй белән әйтеп бирә алды, әсәрнең фабуласын гына булса да хәтерендә яңартты. Зур гәүдәле кавемнең булуына ишарә, геройның килеп чыгышын ханнар, ханбикәләр белән бәйләү, эпос героеның читкә чыгып китүе, аңа ярдәмгә килүче хатын-кыз, эпос героеның алыштыргысыз аты, думбыра чиртеп җыр әйтү, каһарманны таныту – төрки эпоска характерлы әһәмиятле мотивлар. Әлбәттә, сүз бу очракта күләмле эпос-дастанны тулы килеш язып алуга ирешү турында бара алмый, әмма Азнакайга оештырылган экспедиция табышы телдән башкарыла торган эпос традицияләренең һәм мотивларының ныклыгын, дәвамчанлыгын күрсәтә. Ул «Алпамыш»ның бүген дә исәнлеген, Себердә генә түгел, Идел-Урал буенда да халыкка эпос буларак танышлыгын дәлилли.

## ЙОМГАК УРЫНЫНА

Алпамыш турындагы сюжетка нигезләнгән татар эпосы – үткән һәм хәзерге заман арасында гына түгел, ә традицион тере эпос белән тулаем сүз сәнгате, татар язма мәдәнияте арасында да бәйләүче буын. Шунысын да ассызыклап күрсәтү мөһим: «Алпамыш»ның халык теленнән язып алынган күп санлы сөйләмә һәм язмада чагылыш тапкан китаби вариантларыннан гыйбарәт татар версиясенең тамырлары



**Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының язма мирас үзәге фондларында саклана торган «Алпамыш» һәм башка дастан күчермәләреннән үрнәк**

тере эпик традицияләргә нигезләнеп барлыкка килгән һәм формалашкан. Дастан текстларына салынган милли кодлар аша этнос аңының эволюцияләүче билгеләрен табарга мөмкин. Моның өчен «Алпамыш»ның һәр вариантын аерым-аерым махсус тикшерүгә җәлеп итәргә кирәк; фәнни тикшеренүдә халыкның мәдәният тарихы, этнографиясе исәпкә алынырга тиеш. Теләсә кайсы милли эпосның үзенчәлекләрен дөрес аңлау өчен иң мөһиме – аның идея-сәнгати эчтәлеген нигезле интерпретацияләү, шулай ук буыннан-буынга тапшыру формасын һәм юлларын аңлату. Ни өчен дигәндә сүзнең бүгенге көндә киң даирәгә генә түгел, ә тар даирә белгечләргә дә аз билгеле эпик фольклор материалы хакында баруын онытмыйк.

Татар «Алпамышы»ның элеккерәк чорларда теркәлгән күләмле сюжетлы вариантлары да, соңгы елларда сирәк булса да очрап куя торган фабулалары һәм дастаннан аерымланган эпик җырлар – һәммәсе бүгенге көндә «Алпамыш»ның татар версиясе хакында яңа тикшеренүләр алып баруның әһәмиятен ассызыклый. Дастанның татар версиясе бүгенге көндә дә фәнни даирәнең игътибарына лаек.

**Фоторәсемнәр авторның шәхси архивыннан**

# АРЧА ЧИТЕКЛӘРЕ

**Ләйлә Хәкимова,**
*Арча районы Мәдәният йорты сәнгать җитәкчесе*

Их, Арча читекләре
Чигүле, искитмәле.
Арча читекләре киеп
Урамнан бер үт әле.

2024 елның 22 августында Арча районының Кылачы авылында «Арча читекләре» районкүләм этно-фестивале узган иде. Быел әлеге фестиваль, шулай ук август аенда, киң колач алып, республика күләмендә үткәрелде. Фестиваль татар традицион мәдәниятен, халык иҗатының һәм декоратив-гамәли сәнгатенең иң яхшы үрнәкләрен ачыклау, үзенчәлеген үстерү,











онытыла барган борынгы йолаларны, гореф-гадәтләрне торгызу, халык җыр-биюләрен саклап калу, киләчәк буыннарга җиткерү, катнашучы иҗат коллективларына тәҗрибә туплау, читек чигү осталарын, һөнәрчеләрне барлау, күн кәсепчелеген, татар халкының милли аяк киеме – читекне популярлаштыру максатларында үткәрелә.

Әлеге фестивальнең нәкь менә Кылачы авылында башланып китүе юкка түгел. Кылачы – Арча милли аяк киемнәре берләшмәсенең чишмә башы. Биредә яшәүче авыл кешеләре күнне бизәкләп эшләү технологиясен беренчеләрдән булып җәелдереп җибәргән халык.

1885 елда Рамазан һәм Вәли Гайнуллиннар эш эзләп, Казанга юл тоталар. Биредә алар читекләр тегү белән шөгыльләнүче Солтан байга ялланып, бу һөнәргә өйрәнәләр. Авылның башка егетләрен дә шунда эшкә урнаштырырга ярдәм итәләр. 1925 елга кадәр Кылачының дистәләгән кешесе Казанда милли аяк киемнәре җитештерүдә эшли. Ике ел эчендә милли аяк киемнәре җитештерүне тулысынча үзләштерәләр дә, Гайнуллиннар авылга әйләнеп кайталар.

Аннары Кылачының үзендә дә күн аяк киеме эшләүче берләшмә оеша. Ул 1973 елга кадәр эшли.

Бүгенге көндә авылда кеше күп яшәми. Шуңа да карамастан, Кылачыда үзләренең татар халкының милли аяк киеме – читек-чүәкләр ясаучы авыл икәнен онытмыйлар. Биредә, клуб бинасында, авыл тарихына багышланган музей булдырылган. Анда танылган Кылачы читекләре дә урын алган.

Арчада узган быелгы фестивальдә республиканың 7 төбәгеннән – Алексеевск, Биектау, Арча, Әтнә, Нурлат, Балтач районнарыннан, Казаннан килгән 35 иҗат коллективы, үзешчән сәнгать осталары чыгыш ясады. Алар милли йортларда читек тарихын чагылдырган күргәзмә, район һөнәрчеләренең кул эшләнмәләре белән танышты, күн мозаикасы, «Казан җое» һәм читек чигүгә




Арча читекләре
этно-фестивале



багышланган осталык дәресләрендә катнашты. Бәйрәмнең тантаналы өлеше Арча районы Мәдәният йортының «Хәзинә» фольклор коллективы әзерләгән театраль күренеш белән башланып китте, алар Вәли һәм Рамазан Гайнуллиннарның каладан Кылачы авылына кайтуын күрсәттеләр.

Катнашучыларны Арча районы башлыгы урынбасары Алсу Мөхәммәтова сәламләп:

– Читекләр Арча данын еракларга таратkан. Без үзебезнең тарихыбыз белән чын күңелдән горурланабыз. Булдыра алганча шушы тарихны сакларга, үстерергә, киләчәк буынга тапшырырга тырышабыз, – диде.

«Читек – ул Арчаның бренды. Шуны аңлап зур күләмле фестиваль оештыручыларга рәхмәт. Киләчәк буыннарга җиткерерлек әлеге бай мирасны үстерүдә, аны таныту да зур уңышлар телим», – диде Татарстан Республикасының Мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге методисты Миләүшә Насыйбуллина. Һәм әлеге фестивальне оештыруда зур өлеш керткән Арча районы Мәдәният йорты директоры Марат Котдусовка, «Җидегән чишмә» Арча халык театры җитәкчесе Инсаф Мөхәммәтгалиевка, әлеге театрның режиссер ярдәмчесе Гүзәл Нигъмәтҗановага Татарстан Мәдәният министрлыгының Мәдәни ресурс үзәге Рәхмәт хатларын тапшырды.

Фестивальдә катнашучылар өчен «Читегемне күрегез!» бәйгесе игълан ителде: һәр катнашучы, иҗат коллективы үзе белән сувенир

читек ясап алып килергә тиеш иде. Күргәзмәдә кулдан ясалган нинди генә читекләр юк иде. Читекләрне кәгазь, агач, тукыма, хәтта гипстан ясаучылар да булды. Бәйге нәтиҗәләре буенча иң үзенчәлекле читек ясаучылар булып, Алексеевск районыннан «Ак калфак» фольклор төркеме (җитәкчесе – Рәисә Миңнебаева) һәм Арча районы Үрнәк авыл җирлегеннән «Дуслык» фольклор коллективы (җитәкчесе – Алисә Дорохунова) табылды. Һәр катнашучыга истәлекле бүләкләр, Диплом тапшырылды.

«Арча читекләре» фестивале милли традицияләрне буыннан-буынга тапшырырга, милли һөнәрләрнең әһәмиятен һәм бай мирасын яңадан торгызырга ярдәм итә.

**Фоторәсемнәр авторның шәхси архивыннан**





# Татарларның яшерен теле

**Галимҗан Гыйльманов,**
*язучы, әдәбият белгече*



**Әйе-әйе, татарларның яшерен теле бар. Чынлыкта һәр халыкта бар андый тел. Монда әйтергә теләгән атаманы яки фикерне гамәлдә булган гадәти тел кануннары, кулланылыштагы сөйләм нормалары буенча түгел, бәлки, бөтенләй башка, көтелмәгән мәгънәдәге сүзләр, сүзтезмәләр, җөмләләр белән белдерү хакында сүз бара. Төп мәгънәдәге сүзләрне, сүзтезмә-җөмләләрне башка мәгънәдәге сүзләр белән алыштырып, ягъни, яшерен тел кулланып аралашу хакында сөйләшербез бүген.**

Татарда тел яшерү дигән сүз дә бар. Ләкин бу төшенчәгә салынган мәгънә турыдан-туры милли йолалар, әхлакый кануннар, гореф-гадәт традицияләре белән бәйле. Тел яшерүнең төп мәгънәсе – дәшмәү. Ул күбрәк үзара аралашу, туй-никах йолалары, гаилә кодексы кысаларында карала һәм, нигездә, борынгы әхлакый карашлар, ышанулар белән аңлатыла. Тел яшерү (дәшмәү) белән янәшә йөри торган тагын бер милли йола бар – тел ачтыру (бүләк биреп тел ачтыру), дәшәргә, сөйләргә күндерү.

Яшерен тел белән тел яшерүне һич кенә дә бутарга ярамый. Шулай да, алар арасында уртаклык та бар: икесе дә борынгы халык миф-риваятьләренә барып тамырланалар.

ЯШЕРЕН ТЕЛ жанры мифология һәм лингвистика фәннәрендә берничә юнәлешне берләштергән гыйльми өлкә буларак өйрәнелергә лаек. Аның барлык тармакларына да кереп тормастан, без әлеге язмабызда бу темага караган кайбер үрнәкләрне телгә алу белән чикләнәбез.

Бик ерак китмичә, сүзебезне гаилә эченнән башлыйк. Гаиләне ныгытып торучы, аны хәрәкәткә китерүче һәм аның бәрәкәтен, максатын, мәгънәсен билгеләүче балалардан сүз башласак, дөрес булыр.

БАЛА дип әйтү, «бала» сүзен, аның исемен кушып сөйләшү – борынгылыкта иң тыелган гадәтләрнең берсе. Баланы (бигрәк тә яңа туган нарасый-сабыйларны) кирәкмәгән шаукымнан, кара сихердән, күз тиюдән, бозымнан саклау өчен кирәк булган. Бу очракта әлеге дә баягы яшерен тел кулланылган да инде.

Иң әлек бөегебез Нәкый Исәнбәт исемен телгә алу дөрес булыр. Мифологиядәге бу күренешкә ул игътибар иткән. Үзенең «Балалар фольклоры» дигән китабында ул «бала» сүзен «тукмак» сүзе артына яшереп биргән. Билгеле инде, бу гамәл явыз рухлардан, җеннәрдән, шайтаннардан яшереп шулай эшләнгән. Элгәреләр сабыйларын, тез өсләренә утыртып, такмак әйтеп, көйләп сөйгәннәр:

Үчтеки, үчтеки,
Үсмәгәнгә кечтеки.
Йоп-йомыры тукмак,
Әнә бара сукмак,
Күккә кадәр китәрсең,
Бәхетеңә җитәрсең...

«Бала» («балам», «улым», «кызым») төшенчәсенең мәгънәсен татарның яшерен телендә берничә дистә сүз белдерә. Алар арасында «җәннәт кошы» дигән поэтик яңгырашка ия, изгелеккә, илаһилыкка, аерым алганда, сабыйларның гөнаһсыз булуына ишарәли торган сүз дә бар, шулай ук халык иҗатындагы иң популяр образлар – күбәләк, карлыгач, тургай, былбыл, сандугач, күгәрчен кебек сүзләр дә җитәрлек. Бишектә яткан бала елый башласа, ата белән ана бер-берсенә: «Әнә былбыл сайрый башлады», – дип елмаеп дәшә торган булганнар. К. Насыйри язып калдырган табышмакларда да шушы образ кулланыла. Бишектә тирбәлүче бала бик матур поэтик картина аша тасвирлана:

Югары менәр, һи-һи,
Түбән төшәр, һи-һи,
Уртасында былбыл кош.

Аңлап алгансыздыр инде: борынгылар, төрле явыз рухларның игътибарын балаларга юнәлтмәс өчен, «балам», «улым», «кызым» сүзләре урынына күпчелек очракта тереклек ияләренә, кошларга, бөҗәкләргә бирелгән исем-атамалар кулланганнар. Мондый яшерен тел элементлары аеруча әфсен-төфсеннәрдә күп кулланылган.

**Баланы йокыдан уятканда әйтелә торган бу әфсен – шуның бер мисалы:**

Тор, тор, тургай,
Таң-таң ата бугай.
Тургай, кил, чыпчык, чык,
Чырык, чырык, чырык...

**Баланы тәпи җибәргәндә әйтелергә тиешле такмак-әфсеннәр кызык (бу очракта да кулларын як-якка җибәреп, атлап китәргә омтылган бала кошларга тиңләнә):**

Тыпыр-тыпыр киләдер,
Аягы җиргә тимидер.
Очкан коштай талпынып,
Канатларын кагынып,
Тып, тып, тып!

**Баланы карлыгачка тиңләү:**

Тыпый-тыпый карлыгач,
Кунак килсә, казан ас.
Кунак ялгыз ашамас,
Үземнең дә карным ач...

**Ә менә бу очракта карлыгач-балага характеристика бирелә (янәшә «кыргаяк» дигән сүз дә кулланыла әлегә, йөреп китә алмыйча, мүкәләп йөрүче балаларга ишарә), бу лексик берәмлекләрнең һәрберсе «яшерен тел»гә мисал була ала:**

Дүрт аяк, камыт аяк,
Кыргаяк.
Тегәрҗеп муен, төймә баш,
Ник йөрмисең, карлыгач?

**«Кәҗә» сүзе кергән такмаклар белән балаларын тәпи китәргә өйрәтүче ата-аналар да бар:**

Кәҗә, кәҗә, йөр, кәҗә,
Әрәмәгә кер, кәҗә.
Савар идем утырып,
Тустаганны тутырып,
Талдан талга тотынып...
(Күпме кирәк, шулай дәвам итәргә була.)

**Үсмичәрәк торган балаларга карата да яшерен тел үз вариантын бирә:**

Кара тәкә, ак тәкә,
Кайтып килә күк тәкә.
Кеше буй үстергән чакта
Кайда калдың, бүтәкә?
Үс, үс, үстәкә!

Кайчакта халык телендә, «бала» сүзен яшерен телдә әйткәндә, көтелмәгән гыйбарәләр дә очрый: еш кына ата белән ана, бала аларның сөйләшүен ишетмәсен өчен, мыштым гына ашап яисә уйнап утырган газизләренә карап: «Карале, теге авылдагы теге кеше нишли...», – дип сөйләшә башлый; кайчакта, баланың аларны аңламавын күреп: «Башы карабодай саламы белән капланган», – дип тә җибәрәләр...

Иң кызыгы шунда: баланы тынычландырганда әйтелә торган дистәләгән-йөзләгән әфсен-такмакларда «бала» сүзен яшерен телдә әйтү очраклары күзгә чалынмады. Бу очракта «бала» сүзе үзгәртелмичә кулланыла яисә баланың үз исеме атала. Димәк ки, баланың үзе

белән сөйләшкәндә яшерен тел кулланылмый. Менә шундый хикмәтле күренеш.

Балалар белән шулай. «Кеше»нең үз характеристикасы да яшерен тел калыбына төшеп калган. Ул үзенә иминлек, сихәтлек-сәламәтлек теләгәндә, күз тимәсенгә, җен-шайтаннарның игътибарын җәлеп итмәскә тырышып, шушы әфсенне пышылдарга тиеш булган:

Кояшым сүнмәсен,
Суларым кипмәсен,
Тауларым нык булсын,
Йөзләрем ак булсын,
Күңелем пакь булсын!..

Бу әфсеннең борынгы мәгънәсе шундый: Кояш – күзләр, сулар – кан, таулар – сөякләр. Шундыйрак мәгънәдәге әйтемне без борынгы Енисей чөй язуларында – кабер ташларында да очратабыз. Мәсәлән, бер ташка: «Синең кан су кебек акты, синең сөякләр таулар кебек ятты...» – дип уеп язылган.

Балага узу, йөкле булу да элек-электән яшерен тел байлыгы белән белдерелгән. Изгелек-илаһилык дәрәҗәсендәге бу могҗизаның да кара көчләрдән, явыз күзләрдән читтәрәк булуын теләгәннәр. Пермь якларында кияүнең кыз куенына керүен «тун ябу, «яулык ябу» дигән сүзтезмә аша белдергәннәр. Балага узган хатынкай хакында борынгылар, ирен чите белән елмаеп: «Кибән астына тычкан кергән», – дигәннәр. Егетләргә атап җырлана торган җырларда да шул ук символ кулланыла:

Егет булсаң, бул егет,
Көмеш койдыр каеш йөгәнгә.
Егет, гомереңне әрәм үткәрмә, –
Кибән койдыр сөйгәнгә!

Шул ук Пермь татарларында, Удмуртия якларында никах укуны «кәбен салу», никахлашуны «кәбен кою» дип йөрткәннәр.

Гадәттә, яшерен тел сүзләре җанга якын, кадерле, газиз әйберләргә илаһи һәм рухи затларга карата кулланылган. Мәсәлән, фәрештә сүзе дә яшерен телгә «яшереп» куелган. Аңа «канат» дип кенә әйтү гадәте булган. Әйтик, балигъ булган балага шундый теләк теләгәннәр:

Миннән азат,
Ходайдан – канат.

Бу очракта «канат» сүзе «фәрештә» дигәнне белдерә. (Һәр балигъ кешенең фәрештәсе булырга тиеш, димәктән).

Борынгы кеше өчен атлар – изге хайван булып исәпләнгән. Аны бигрәк тә кара рухлар, яман көчләр каршында «фашларга» ярамаган. Шуңа да атларны төрлечә атап йөртә башлаганнар («ат» дип гомумән дә әйтергә ярамаган). Күбрәк төсләренә карап атаганнар: тимеркүк, алмачуар, кашка, туры һәм башкалар; яисә тоякларына карап аерганнар: «тимер тояк», «мамык тояк» һәм башкалар. Атның холкына, яшенә, гәүдә төзелешенә карап бирелгән атамалар да бар. Аларның күбесе әфсен текстларына төшеп калган. Мәсәлән, чабышкы атларны Сабантуйның бәйге мәйданына колакларына шушы әфсенне пышылдап алып чыкканнар:

Аягыңа – мамык тояк,
Колакларың – суган кыяк,
Яшен-камчы кулымда,
Беренче бул юлыңда!

Күрәсез, ничек кенә имләсәләр дә, текстларда «ат» дигән, яисә «айгыр», «байтал» дигән сүзләр кулланмаганнар.

Орлык чәчәргә вакыты җиткән айгыр хакында да, яшерен тел белән: «Билен бөккән», – дип әйтә торган булганнар.

Җырлы, моңлы кешеләр турында борынгылар: «Авызы белән кош тоткан», – дигәннәр.

Сугыш коралларына, пычак-хәнҗәр ише үткен коралларга да үз исеме белән әйтмәскә тырышканнар. Исем-атамасы белән әйтсәң, имеш, сиңа ярарга тырыша башлый: кисә, кадый... Шулай афәт китерергә мөмкин, дип ышанганнар. «Кан» сүзе исә еш кына «кызыл» сүзенә алыштырылган. Бик борынгы «Күк керде, кызыл чыкты» (Кашгарый сүзлегеннән)

«

**Борынгылар, төрле явыз рухларның игътибарын балаларга юнәлтмәс өчен, «балам», «улым», «кызым» сүзләре урынына күпчелек очракта тереклек иярәренә, кошларга, бөҗәкләргә бирелгән исем-атамалар кулланганнар. Мондый яшерен тел элементлары аеруча әфсен-төфсеннәрдә күп кулланылган.**

«

дигән әйтемдә дә «күк» – кылычны яисә хәнҗәрне белдерсә, «кызыл» җәрәхәттән аккан канны гәүдәләндерә.

Борынгылар өчен учак күмере бик мөһим булган. Учак сүнү еш кына гаиләнең, кабилә-ыруның фаҗигасенә әверелгән. Шуңа да күмерне аеруча нык кадерләгәннәр, хөрмәтләгәннәр, аннан кешегә тимәвен үтенгәннәр. Уттан курку хисе дә булган, әлбәттә. Ут-учак белән аңлашырга тырышканнар, аның белән компромисс эзләгәннәр.

Ал чәчәк, гөл чәчәк,
Күтәрергә авыр чәчәк.
Тимәсәнә кулыма!

* * *

Күрер күзгә җиңел чәчәк,
Күтәрмәгә авыр чәчәк,
Аллы-гөлле матур чәчәк,
Тимә минем кулыма!

Яшерен тел бөрәмлекләре әфсен текстларында күп очрый. Без бу хакта үткәндәге язмаларыбызда кат-кат әйткән идек инде. Бигрәк тә табигать әфсеннәрендә үзе бер билгесез (яшерен) тел яши. Шуларның берничәсен генә хәтеребездә яңартыйк.

Элек-электән куркыныч табигать күренешләрен үз атамасы белән әйтергә ярамаган. Менә хәтәр яңгыр болытын ничек сурәтләгән борынгы кеше (аның символын читтән эзләп тормаганнар, янәшәдәге мал утарыннан тапканнар):

Каты-каты басып,
Кола сыер килә.
Тулы имчәгеннән
Сөте тамып килә...

Яисә яшен яшьнәү күренеше. Аны инде утардагы кашка тәкәгә тиңләгәннәр, шунда ук чәбәләнеп яткан алтын балыкны да күзалларга тырышканнар, бәхилләтер өчен, яшен каршына балык тәңкәсе сипкәннәр...

Менә сиңа бүләккә
Алтын балык тәңкәсе.
Утарыңа кереп ят,
Алланың кашка
тәкәсе!

Яшенгә «Елдырым!» дип, йомшак итеп әйтү дә бар. «Елдырым, мине исән калдырың!» – дип тә сораганнар. Миф буенча, шулай матур сөйләшмәсәң, ул ташларын атачак, имеш. Чынлыкта (миф буенча) яшен: «Шайтанга, җенгә сугам!» – дип суга, ди. Күк аткан (суккан) шайтаннар, җеннәр шулай яшен ташы булып төшә, имеш. «Ни өчен кешеләрне яшен суга соң, алайса?» – дип сорарсыз. Чөнки утлы таш белән аска атылган шайтаннар, җеннәр кайчакта кешеләргә яшен утының зәһәрен биреп өлгерәләр, ди. Ә инде яшен суккан шайтан урманга төшсә – Убыр, суга төшсә – Су анасы, җиргә төшсә – Албасты була, ди. Яшен ташы үзеңә тимәсә дә, бу түбән рухлар кешегә бик зур зыян салачак, имеш...

> «
> **Борынгы кеше өчен атлар – изге хайван булып исәпләнгән. Аны бигрәк тә кара рухлар, яман көчләр каршында «фашларга» ярамаган. Күбрәк төсләренә карап атаганнар: тимеркүк, алмачуар, кашка, туры һәм башкалар; яисә тоякларына карап аерганнар: «тимер тояк», «мамык тояк» һәм башкалар.**
> «

Мифология буенча мәгълүм рухларны, ияләрне дә үз атамалары белән әйтергә кушмаганнар. Еш кына аларга исем дә кушканнар. Шул рәвешле Җир иясенең – Җирән сакал, Җир анасының – Асыл бикә һәм Сынлы бикә, Су атасының – Суган сакал, Су анасының Сусыл бикә кебек исемнәре барлыкка килгән.

Яшәешнең иң серле вакыты – ул төн. Ә төннең төп персонажлары Ай белән йолдызлар. Бу шаукымлы мәлдә әлеге күк җисемнәрен дә үз төшенчәләре белән атарга ярамаган. Яшерен тел кулланып, тулы Айга – «таба», яшь (һилал) Айга «урак» дигәннәр, ә йолдызларны «энҗе-мәрҗәннәр» белән тиңләгәннәр. Сүз уңаеннан: борынгы төрки баба Кояшка еш кына «утлы таба» дип мөрәҗәгать иткән.

Кара өермә купса да, аңа үз атамасы белән дәшәргә ярамый, яшерен телгә күчеп, «пычак» дип әйтергә кушалар, хәтта өермә эченә пычак, пәке ташларга да ярый, шуннан

соң ул басыла, имеш. Димәк ки, өермә йомшак сүзне аңламый, аңа карата каты сүзле, каты куллы булырга кирәк. Һәрхәлдә халык мифы шулай ди.

Урманда йөргән кеше дә яшерен телне яхшы үзләштергән булырга тиеш. Әйтик, сиңа аю очрый, ди... Аю очрамаса да, «аю» дип кенә әйтсәң дә, ул кинәт каршыңа чыгарга мөмкин. Яшерен тел кануннары буенча урманда аю турында «бабай» дип сөйләргә тиеш булабыз. Хәтта аю инде каршыңа чыккан булса да, «бабай» дип дәшәргә кирәк, «Нихәл, бабай», – дип исәнләшсәң, тагын да әйбәтрәк. Әлбәттә инде, исәнләшү белән читкә китү ягын карарга кирәк...

Урман, әрәмәлек буенда тагын бер куркыныч җан иясе – елан. Юлыңда очраса-очрамаса да, кырда, урманда «елан» дип әйтергә ярамый. Яшерен телдә аның үз атамалары бар: «камчы», «каеш», «ботак»... Халык телендәге әйтем-табышмак та шуңа ишарәли: «Яланда майлы каеш ятар». Бу бик борынгы әйтем. 1303 елга караган «Куман мәҗмугасы»нда ук аның «Язына яулы каеш ятыр» дигән варианты бар. Инде күргән яисә шикләнгән очракта, аны юлдан яздыра торга әфсен текстлары да җитәрлек. Менә аларның берсе:

Алтын аел,
Кара каеш,
Менә ботак,
Шуңа кавыш!

...Кешелек тормышында мөһим роль уйнаган кайбер сүзләрне дә башка сүзләр белән алыштыруны, шул рәвешле шайтан коткысыннан саклануны хуп күргәннәр. Мәсәлән, безнең бабайлар акчаны «дөнья иманы» дип йөрткәннәр, ә зиратны, каберлекне «төтенсез авыл» дип атаганнар...

Яшерен тел, әлбәттә, кешеләрнең яшәү рәвешенә, гамәл-хәрәкәтләренә, күңел һәм характер сыйфатларына да кагыла.

Яшерен телгә караган тел берәмлекләре (лексика) аеруча мәкаль-әйтемнәргә, табышмакларга күпләп «төшеп калган». Кычкырып әйтергә ярамаган чакта татар кешесе үзенең эзоп телен бик тиз «уйлап тапкан». Менә шуларның берничәсе:

Кара сакал – фәкыйрьлек;
Буш куллы – фәкыйрь;
Суык (салкын) куллы – карак;
Бүре сырхавы – ачлык;
Эчле-тышлы – ихлас түгел;
Күңел кошы – акыл;
Тәртәсе кыска – сабырсыз;
Тиресенә сыймый – тәкәббер;
Коры сурәт – һөнәрсез, булдыксыз;
Пешкән кеше – дөнья күргән кеше;
Ярык барабан (тел бистәсе) – мәгънәсез сүзләр сөйләүче, һәм башкалар.

Борынгылар, алардан күрә бүген дә татарлар эше барып чыкмаган кеше хакында «Көймәсе комга утырды» дип сөйли. Ә нияте, максаты гамәлгә аша башлаган кеше турында «Капкасы ачыла башлады» дип хәбәр итәләр.

Яшерен тел, сүз алыштыру «сак сөйләм»дә, шаукымлы сүзләрне әйткәндә дә кулланылырга мөмкин. Әйтик, «китәм» дигән сүзне бик сак әйтергә кирәк. Бу фигыль сүзендә соңгы юлга китү (үлү) күзаллана. «Китәм» дигән мәгънәдә булса да, бәласеннән башаяк, иң яхшысы «барам», «кайтам» сүзләрен куллану: «Мин шәһәргә барам» яисә «Мин авылга кайтам».

Аннары, кемнедер бәйрәме, туган көне, юбилее белән котлаганда, бик нык әйтергә теләсәгез дә: «Мәңге шулай яшь булып кал!» – димәгез. Бу котлавыгыз «картайма, шул яшь килеш кал, башка яшәмә» дигән мәгънәгә алып чыга. Чын дөресен әйтегез: «Шулай матур булып, сау-сәламәт картаерга язсын!» – диегез.

Шунысы да бар: «Каяртаям!» дип, авыз тутырып әйтергә дә ярамый. Шулай дигән саен кеше йөзендә бер җыерчык, сыр арта, имеш. Инде кемдер: «Мин картаям», – ди икән, аңа җавап итеп: «Карт аю урманда гына була ул», – дип әйтергә кирәк. «Картаям» дип бик әйтәсең килә икән инде, яшерен тел кулланып: «Яшь аю белән дус түгел әле», «Яшь аю ташлап китте, юньсез», «Яшь аю тоттырмый бу арада», дип, елмаеп котылырга мөмкин.

Һәр әйтелгән сүзнең, хәтта яшереп әйтелгән сүзнең дә көче бар – шуны онытмыйк!

**САНКТ-ПЕТЕРБУРГТА БҮГЕНГЕ КӨНДӘ ИКЕ ТАТАР ТЕАТРЫ ЭШЛӘП КИЛӘ. БЫЕЛ АЛАР ИКЕСЕ ДӘ ТАМАШАЧЫГА СПЕКТАКЛЬ ТӘКЪДИМ ИТТЕ. ШУНЫСЫ ИГЪТИБАРГА ЛАЕК – ТЕАТР СТУДИЯЛӘРЕ ҮЗЛӘРЕ ДӘ, АЛАР ЧЫГАРГАН СПЕКТАКЛЬЛӘР ДӘ БЕР-БЕРСЕН КАБАТЛАМЫЙ. «ПИТЕРДА НӘКЪ МЕНӘ 2 ТАТАР ТЕАТРЫ БУЛУЫ – УҢАЙ КҮРЕНЕШ. БУ – СӘЛАМӘТ КОНКУРЕНЦИЯ ТУДЫРЫП, АЛАРГА ҮСЕШ ӨЧЕН МӨМКИНЛЕК ТУДЫРА», – ДИДЕ, КАЗАННАН СПЕКТАКЛЬЛӘРНЕ КАРАРГА КИЛГӘН, БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ ДАНИС ШАКИРОВ.**

**Рузилә Мөхәммәтова,**
*журналист*

# «БЫЛБЫЛ» *театры – чын театр»*



...Бетеп барган авыл. Биредә 1 бабай һәм 3 әби генә яшәп калган. Барысы да авыл интеллигенциясе – элеккеге рәис, завклуб, фельдшер һәм укытучы. Яшәп яталар матур гына: чишмә суы агып тора, бакчада бәрәңге үсә, тавыклар чүпләнә, мунчага каен себеркесе бар, иң мөһиме, балалар кайтып, хәл белешеп тора. Әбиләр традиция буенча көн саен җыелып, яшьлек хатирәләрен яңарта-яңарта чәй эчә. Шул чакта авылга социаль яклау хезмәткәре килеп, әбиләрне һәм бабайны картлар йортына китәргә үгетли башлый. Әмма икенче юл табыла – авылдан чыккан эшмәкәр, авыл чишмәсенең файдалы үзлекләрен ачыклап, бетеп барган авыл урынында санаторий ача. Шулай итеп җәннәткә тиң җирләр әрәм ятмый, монда кеше агыла, тормыш кайный башлый. Кыскасы, тамашачы беренче бүлектә әби-бабайның авылда узган яшьлек хатирәләренә чумса, икенче бүлектә «Алтын чишмә» санаторие ачылышының шаһиты була.

Катнашучылар: санаторий ачучы эшмәкәр Илдар ролендә – эшмәкәр, «Европа татарлары альянсы» халыкара ассоциациясе идарәсе әгъзасы, икътисад һәм хокук магистры, меценат Кыям Курмакаев; Илдар әфәнденең әнисе Гөлфия Шәмсиевна ролендә – Флорида Хәмидуллина; клуб мөдире Илсөяр ролендә – Зифа Иванова; элеккеге колхоз рәисе Мөдәррис ролендә – Азамат

**БЕЛЕШМӘ:**

***«Былбыл» Санкт-Петербургта оешкан беренче татар халык театры. 2021 елның 2 октябрендә ул тамашачыга беренче спектаклен күрсәтә.***

***«Былбыл» Санкт-Петербургның «Рыбацкий» мәдәният йортында урнашкан. Театр әлеге Мәдәният йорты коллективлары исемлегенә кергән.***



***«Театрның әтисе» дип, Санкт-Петербург татар-милли мәдәни автономиясе рәисе урынбасары, меценат Шамил Алюшевны атыйлар.***

***«Былбыл» татар халык театры быел тамашачыга «Алтын чишмә» спектаклен тәкъдим итте.***

***«Алтын чишмә» – коллективның бишенче спектакле. Театрның беренче спектакле Флорид Бүләков пьесасы буенча куелган «Әбиләргә ни житми?» моңсу комедиясе, икенчесе – «Әстәгыфирулла», өченчесе – «Шүрәле» эксперименталь спектакле, дүртенчесе – «Йөрәк сере» (француз язучысы Робер Томның «Сигез хатын-кыз» детектив комедиясе).***

***«Алтын чишмә» спектакле өчен пьесаны театрны оештыручы, житәкчесе Сиринә Зиннурова үзе язган.***

Рәхимов; социаль яклау комитеты вәкиле Илһам ролендә – Альберт Габитов һәм, әлбәттә, Сиринә Зиннурова үзе – авыл фельдшеры Вәсилә ролендә. Спектакльдә, санаторий кунаклары булып, театрның дуслары, шул исәптән, супертатар әбиләре – Венера һәм Роза Гарәфетдиновалар чыкты. «Санаторий ачылу тантанасында» Питерның иң милли киемле ханымы Линара Николашкина һәм татар эшмәкәре Кыям Курмакаев җырлады.

Әйе, авылда яшәүчеләргә картлар йортына китеп тә тормышны дәвам итәргә яисә, «кирегә катып», шушы авылда да яшәп торып була. Автор монда башка бер чишелеш күрсәтә – без бит оҗмахтай урыннарда яшибез, шушы җирләребезгә игътибар белән карасак, сәламәтлек һәм байлык чыганагы бит ул урыннар, ди. Биредә татар эшмәкәренең идеаль образы күрсәтелә: әнисен бетеп бара торган авылдан алып китә алмаган икән, ул яшәгән урынны халык кайнап торган урынга әверелдерә – санаторий ачып, халыкны эш урыннары белән кызыксындырып, бирегә кайтара. «Үз җиребезне үзебез гөлбакча итик, үз меценатларыбызга ышанайк – алар бар әле», – ди спектакльне куючылар. «Татарның язмышы үз кулында» дигән асыл мәгънә тойдым мин спектакльдә. Бу спектакльгә гаҗәеп зур оптимизм һәм позитив энергетика салынган иде.

«Былбыл» театрын карарга Казаннан бер төркем кунаклар килеп төшүе дә театр студиясе өчен зур бүләк булгандыр. Чөнки ул көннәрдә Санкт-Петербургта Кариев исемендәге Казан яшь тамашачы театры гастрольләре бара иде.

– Мин халык театры тууына шатланып утырдым – котлыйм. Бу – зур вакыйга! Юктан бар итү – ул бик авыр. Мин сезнең спектакльне карап, үзем өчен зур ачыш ясадым – сезнең бөтен әйберегез чын булды: чын хисләр, чын декорацияләр... Дивардагы сәгатьне күрдегезме – йөреп торучы чын сәгать, өстәлдәге ризыкларын күрдегезме – чын ризыклар иде. Бу – тере театр булуы белән кадерле, – диде Кариев театрының баш режиссеры Ренат Әюпов.

Иң кызыгы шунда – спектакль беткәч, аның икенче сериясе башланды кебек. Чөнки тамашачы кайтырга ашыкмады. Сәхнәгә менеп тә, менмичә дә котлаулар, җылы сүзләр, рәхмәтләр, чәчәкләр, бүләкләр, менеп-төшеп фотога төшүләр, дисеңме... Артистлар белән тамашачы бер дулкында иде. Ниндидер гаҗәеп дулкын иде ул. Дәвамлы булсын!

**«Алтын чишмә» спектакленнән күренешләр**
**Рузилә Мөхәммәтова фоторәсемнәре**

# ПИТЕР *татарлары* спектакль УЙНЫЙ

**Питер татар театры коллективы шактый катлаулы әсәргә алынган – төрек язучысы Тунҗер Җүҗеноглуның «Ташкын» драмасын сайлаганнар: бу – һәвәскәр артистлардан тупланган коллектив өчен гаять зур батырлык, үз көченә нык ышаныч һәм сәламәт амбицияләр.**

**БЕЛЕШМӘ:**

***Санкт-Петербург каласының Питер татар театры үз эшчәнлеген 2023 елда башлап җибәрә.***

Питер татар халык театры профессиональлеккә йөз тоткан театр. Катлаулы драма әсәре сайлап алар шушы профессиональлекне, үзләренең үсештә булуын күрсәтергә омтыла.

Спектакльдә катнашалар: Яшь егет – Линар Хаҗиев (театр режиссеры), Яшь кыз – Гүзәл Исмәгыйлева (театр җитәкчесе), Әби – Розалия Кәрамова, Бабай – Рамил Атангулов, Ир – Илшат Дәүләтбаев (театр реквизиторы), Хатын – Альбина Шәмсетдинова, Рәис ханым – Рәхимә Фәхриева, Кендек әбисе –





*Театрның җитәкчесе – Гүзәл Исмәгыйлева. Баш режиссеры – Линар Хаҗиев.*

*Театр Татарстанның Санкт-Петербург һәм Ленинград өлкәсендәге даими вәкиллеге хәерфатихасы белән эшли башлый.*

*Репетицияләр Санкт-Петербургның «Мирас» мәдәният үзәгендә үткәрелә.*

*Театр үз спектакльләрен Герцен исемендәге Россия дәүләт педагогика университеты залында күрсәтә.*

Гөлсем Мирсәетова, Күмелгән кызның өрәге – Эльмира Әхмәтова (театр хореографы һәм костюмеры), Бабайның абыйсының өрәге, каравылчы – Равил Ибраһимов. Шулай ук, төрле рольләрдә Резидә Арсланова һәм Эльдар Мурдашев катнаша.

Сәхнә әсәрендәге вакыйгалар таулар арасында утырган авылда – өч буын яшәгән йортта бара. Бу авылда 9 ай буена тавыш чыгарырга ярамый, чөнки тавыштан таулардагы кар ишелергә мөмкин. Шуңа кешеләр пышылдап сөйләшә, көлми, кычкырмый, туй ясамый, бала тапмый... Әмма яшь киленнең көтмәгәндә тулгагы башлана. Без спектакль дәвамында, шушы кыска гына вакыт эчендә, бу гаиләдә дөньяның асты өскә килүен, кешеләрнең чын йөзләрен күрәбез.

Спектакльдә күп темалар үрелә, әлбәттә, ул – таулар һәм ташкын турында түгел. Бу әсәрдә буыннар конфликты да, гаилә конфликты да, кешеләрнең үзләренә кагыйдәләр уйлап табып, шуннан үзләре үк газаплануы да бар. Киленнең вакытыннан алда тулгагы башлануы турында аксакаллар шурасына җиткереп (кызны үтерәчәкләрен белә торып), алар беренче чиратта нәрсәдән курка – кешеләр һәм шул исәптән үзләренең дә үлемен-нәнме, әллә закон бозуданмы, нишләп гаилә үз әгъзасын саклап,









яшереп калырга тырышмый? Шушы нечкә мизгелләрне бирә алды бит артистлар – үз оныкларын карынында йөрткән хатынны саклап калырга теләмәгән ата белән ана рольләрен башкаручы Илшат Дәүләтбаев һәм Альбина Шәмсетдиновага шушы эпизод өчен генә дә афәрин! Ә авырлы килен ролендәге Гүзәл Исмәгыйлеваның төпсез күзләрендә үзен алда ни көткәнен фаразлау гына түгел, кемнәр арасында яшәгәнен аңлау да бар. Хәтта чын тулгакны да менә дигән итеп күрсәтә алды. Картны уйнаган Рамил Атангуловның да нииндидер бер эчке көче бар. «Бер ай укый-укый, миңа бирелгән текстның бер кисәген ятлый алдым. Аннары минем тирәмдә остазлар барлыкка килде – өйрәтә башладылар. Ике ай дигәндә бер бүлеген өйрәндем. Линарга рәхмәт – аның уенына да, режиссерлыгына да сокланып карадым. Гаҗәп бит! Телевизордан карт бабайлар булып уйнаган артистларга игътибар итә башладым. «Мин булдырам!» – дидем үземә. «Монда килгәнмен икән, мин – артист!» – дидем», – дип сөйли Рамил Атангулов.

Әлеге пьеса буенча куелган спектакльнең финалын ачык калдырып та булыр иде. Ә театр аны оптимистик рухта бетергән. Бала туды… Театрның, бала туган кебек, спектакле дә туды.

«Ташкын» спектаклен чыгарган Питер татар халык театры бу әсәре белән төрле фестивальләрдә, аерым алганда, «Идел-йорт» халык театрлары фестивалендә катнашу мөмкинлеген карый. Катнашу гына түгел, аларның гадел ярышта уңышка ирешәсенә дә ышанычым зур.

**Тунҗер Җүҗеноглуның «Ташкын» драмасыннан күренешләр**

**Лилия Ибраһимова фоторәсемнәре**

# «Садә»ләләр тарихыннан...

Без, без, без идек –
Авырлыклар күп күрдек.
Картайдык, дип утырмыйбыз,
Тагын сәхнәгә мендек...

Әлеге шигырь юлларын, моннан 46 ел элек, 1979 елның февраль аенда Апас Мәдәният йорты каршында оешкан, хезмәт ветераннарыннан гына торган «Садә» ансамбленә йөрүчеләр иҗат иткән. Тора бара бу җыр ансамбльнең гимнына әйләнгән.

«Садә» – район культура методисты, яшь, талантлы баянчы һәм җырчы Илдар Сәйфетдинов тәкъдиме белән оештырылган сәхнә ветераннары вокал ансамбле. Аңа ансамбльгә кешеләр табуда, аларны күндерүдә район культура бүлеге хезмәткәре Мөслимә Кадыйрова (соңрак Мөслимә апа Илдар абыйның тормыш иптәше була), китапханәче Равия Таҗиева (ансамбльнең актив әгъзаларыннан берсе) зур булышлык күрсәтәләр. Ветеран укытучы Мәгъсүмә апа Гыйниятова ансамбльгә «Садә» дигән бик матур исем дә табып бирә. «Садә» сүзе – «аһәңле, бик матур яңгырашлы аваз» дигәнне аңлата. Биредә унсигез ветеран берничә тавыштан җырлау техникасын үзләштерә.

Бервакыт минем кулыма 1979 елның май аенда чыккан «Йолдыз» район газетасының 55нче саны килеп эләкте. Биредә «Садә» ансамбле турында язылган иде. Әлеге сәхифәне «Йолдыз» газетасының актив хезмәткәре булган, мәрхүм Азат Сункишев әзерләгән. «Садә» ансамбле оешканга өч ай булды», – дип яза ул. Һәм ансамбльгә беренчеләрдән булып йөри башлаган садәләләр үзләренең фикерләре белән уртаклашалар. Алар инде күптән бакыйлыкта булсалар да, язып калдырган фикерләре миңа тәҗрибә уртаклашу сыман яңгырый.

**Гөлҗиһан Җамалиева:** Ансамбльгә без Сәкинә Ихсанова, Хафизә Хәбибуллина һәм мин – иң беренчеләрдән булып килдек. Бераздан Мәрьям Минкина, Маһинур Сафина кушылдылар. Инде менә 18әү булдык. Бер-беребезне яшьлек елларыннан ук беләбез. Көр тавыш белән җыр яңгыратучы тиңдәшләремне күрүгә күңелемдә яшәү дәрте яңарып китте. Яшибез әле болай булса, җырлыйбыз әле!

**Хаҗирә Сафиуллина:** Минем сәхнәгә беренче тапкыр менүем 1928 елда булды. Комсомол эше активисты идем. Безнең Урта Балтай да ул чорда волость үзәге иде. Мәчеттән клубка әйләндерелгән бинада «Авыл серләре» исемле спектакль хәзерләдек. Авыл кешесе өчен әр-яңа нәрсә бит. Кеше читенсенер, театрыбызга килмәс, дип, әй курыккан идек шул вакытта, ничек башкарырбыз,



дип әй дулкынланган идек... Юкка шөбһәләнгәнбез, спектаклебезне халык бик яратып кабул итте. Ул чордан бирле 50 елдан артык вакыт үтте. Гомеремнең байтак өлешен сәхнә белән тыгыз дуслыкта үткәрдем, төрле спектакльләрдә күп санлы рольләр башкардым. Тән картайса да күңел картаймый. «Әйдә ветераннар ансамбленә, Хаҗирә апа!» – дигән тәкъдимне ишеткәч, канатланып киттем. Шатланып риза булдым. Ансамбльгә бик теләп яратып йөрим.

**Сара Хөсәенова:** Минем балалык һәм яшьлек елларым бик кыен чорга туры килде. Гражданнар сугышы, ачлык, кыен күтәрелеш еллары... Шулай да яңа тормыш таңыннан нур алып, канатланып яши белдек. Карашлары яңа ачылып, киңәеп килүче авыл кешеләре өчен ул елларда спектакльләрнең тәрбияви әһәмияте гаять зур иде. Сәхнә сәнгатенә мәхәббәт хисен дәвамлы педагогик эшчәнлегемдә укучыларым күңелендә дә кабызырга тырыштым. Мәктәп хоры белән җитәкчелек иттем. Җыр дәресләре алып бардым. Башка ветераннар кебек, «Садә»гә мин дә теләп йөрим.

**Ниса Гомәрова:** Яшьләргә ял итәр өчен уңайлы шартлар бик күп хәзер. Безнең яшьлек елларында алай түгел иде. Сәхнә ясау өчен бервакыт такта җыеп йөргәнебез хәтердә. Клубның үз реквизиты юк, спектакльләргә киемнәр табу өчен әллә нинди хәйләләргә бара идек. Хәзер инде һәр авылда Мәдәният йортлары балкып тора. Иренмәсәң, бик күп кызыклы чаралар оештырырга була. Район Мәдәният йорты соңгы вакытта эшен шактый җанландырды – бу шатлыклы күренеш. Яшьләргә генә түгел, хөрмәтләп, күңелебезне күреп, сәхнәдә без – ветераннарга да урын бирделәр. Монысына да зур рәхмәт. Яшәреп киткәндәй булдык.

**Маһирә Җамалиева:** Хезмәт юлым җәмәгать эше белән тыгыз үрелеп барды. Педагогия училищесын бетереп, 30нчы елларда Шәмәк, Борнаш, Дәвештә, ә 1942 елдан лаеклы ялга чаклы Татар Черкене авылында укыттым. Шушы чорда концерт-спектакльдә гел катнаша идем. Ансамбль җитәкчесе Илдар Сәйфетдинов бик талантлы, сабыр кеше. Рәхмәт аңа!

**Разия Гайнуллина:** Күптәнге, актив һәвәскәр булганлыктан, «Садә» ансамбленә теләп язылдым. Сәхнәдә чыгыш ясаган көннәрдә күңел аеруча канатлана. Тамашачылар алкышына балаларча ихласлык белән шатланабыз. Уены-чыны белән әйткәндә: ансамбльгә йөрүдән таякка таяныр көн җитмичә туктамаячакмын!

**Гүзәл Әхмәтҗанова:** Миндә сәнгатькә мәхәббәт хисен Сара апа Хөсәенова уятты. Класс җитәкчебез иде ул безнең. 1954 елда безнең тугызынчы класс, «Яшьлек иртәсе» исемле постановка белән, сыйныфлар арасындагы бәйгедә беренчелекне яулады. Икенче елда да беренчелеккә ия булдык. Һәвәскәр сәнгатьне озак елларга үз иттем. Тормыш иптәшем Хәниф белән дә театр табыштырды, кавыштырды. Спектакльләрдә икебез дә бик актив катнаша идек. (**Авт.:** *Гүзәл апа бүгенгесе көндә дә исән-сау).*

**Зифа Васильева:** Һөнәрем буенча мин укытучы. Башта – төрле авылларда, сугыш елларында Табар Черкенендә укыттым. Соңгы 31 елда Апас мәктәбендә эшләдем. Биш ел элек лаеклы ялга чыктым. Коллективтан аерылуы җиңел түгел икән. Мәктәптән читтә, күнегелмәгән тынлыкны





**Ансамбльнең иң беренче әгъзаларыннан берсе – Мәрьям Минкина**




тоеп, үзеңне ничектер ялгыз, онытылган бер кеше итеп хис итәсең. Шундый тойгылар белән яшәп ятканда ансамбльгә чакырулары табиблар дәвасы булып күренде. «Димәк онытмаганнар икән, димәк, кешеләр өчен файдалы була алам икән әле», дип шатланып киттем. «Садә» ансамбле йөрәккә дәрт, күңелгә көч бирде.

**Җиһан Шәрәфиева:** Яшь чагымнан ук спектакльләрдә катнаша идем. Концертларда җырлар башкарган вакытларым да аз булмады. Утызынчы елларда мин Апас балалар бакчасында тәрбияче булып эшләдем. Балаларда җырга мәхәббәт уятырга тырыша идем. Ансамбль әгъзалары Нажия Галимҗанова, Тәслимә Әсәдуллина – минем кул астында тәрбия алган кешеләр. Ансамбльгә бик теләп, яратып йөрим.

**Тәслимә Әсәдуллина:** Җиһан апа күңелемдә җыр-музыкага мәхәббәтне бик ныклы итеп уяткан икән. Җырдан һичкайчан аерыла алмам кебек. Көнкүреш хезмәте күрсәтү сферасында 1929 елдан бирле эшлим. Шул чорда агитбригадалар составында күп мәртәбәләр чыгыш ясарга туры килде. Җырга мәхәббәтем һаман да сүрелми. Җыр күңелгә дәрт бирә.

**Дилбәр Галиева:** Мин биш яшемнән җырлый, бии, шигырь сөйли башладым. Һәвәскәрлек һөнәремне гомерем дәвамына юлдаш иттем.

Ә минем гомер юлым җиңелдән булмады. Яшь-яшь килеш сугыш утына кердем. Сугыш тынган араларда исә, дивизия ансамбле составында сәхнәгә менә идем. Сугыштан соңгы елларда нәфис сүз һәм төрле биюләр белән агитбригадаларда актив катнашып йөрдем. Кызык кына хәлләр дә булгалады. Берчак Дәвештә Нажия Галимҗанова белән биегәндә сәхнә урынына куелган парталар аерылды да аяклар төшеп китте. Сиздермәдек, биюне дәвам иттек. Халык «шаян бию» башкаралар дип уйлады. Ә безнең аяклар исә уттай яна, әрни... Ансамбльгә йөрүемә, кабаттан һәвәскәр сәнгать белән шөгыльләнә башлавыма бик шатмын.

**Мәгъсүмә Гыйниятова:** Мин узган олы хезмәт юлының һәр пункты үзешчән сәнгатькә бәйләнешле. Сугышка чаклы укытучылык итү чорында спектакль, концертларга еш катнаша, укучыларны олимпиадаларга әзерли идем. Бер көн шулай кызык кына бер хәл булды. «Мәгъсүмә апа, танйсызмы, безне олимпиадаларга алып бара идегез», – дип, урамда бер хатын туктатты. Карыйм – укучым Зәйнәп Гыйсмәтуллина! Ветераннар ансамбленә йөрергә риза булу гына түгел, аны оештыру, аңа кешеләр тартуда зур булышлык та күрсәттем. Һәрберебезнең теләге бер: гомерең озын булсын, «Садә»!

Бу бит – тарих! Укып чыккач, ул апалар белән күптәннән таныш, барысын да белгәндәй тоелды миңа. Еллар үтә тора... «Садә» ансамбле дә яшәвеннән туктамый.

Узган гасырның 90нчы елларында мәдәният йортына бик чая, сәнгатькә гашыйк Зәйнәп

Яруллина эшкә урнаша. Ул вакытларда мәдәният бүлеген Әгъзам Хәмидуллин җитәкли. Зәйнәп апага «Садә» ансамблен тапшыралар. Чөнки Илдар абый музыка мәктәбен җитәкли башлау сәбәпле, ансамбльгә вакыты җитми. Зәйнәп апа бераз куркып калса да, бу эшкә ныклап тотына. Нәкъ менә ул җитәкчелек иткәндә ансамбльгә ике гармунчы килеп кушыла – Бәнат апа Галиәкбәрова үзенең яшьлек дустын Рауза апаны да чакыра. Ике оста гармунчы «Садә»гә йөрүчеләрне биетәләр дә, җырлаталар да.

Зәйнәп апа җитәкләгән вакытта беренче чыгышлары Җиңүнең 50 еллыгына багышланган Республика күләмендәге фольклор фестиваль була. Тырыш җитәкче музей документларына, альбомнарга, фронттан килгән өчпочмаклы хатларга һәм булган хәлләргә таянып, «Язлар Җиңү алып килде» дигән тамаша әзерли. Республика фольклор Үзәге җитәкчесе Котдус Хөснуллин тамашаны карагач, бөтен коллектив алдында Зәйнәп апага һәм ансамбльгә йөрүче апаларга рәхмәтен белдерә. 73 коллектив арасында лауреат исеменә лаек була алар. Бүгенге көндә Зәйнәп апа Яруллина иң актив әгъзаларның берсе.

Соңрак ансамбль белән җитәкчелекне Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Резеда Мостафина үз өстенә ала. Шулай итеп состав яңара, апалар да алышына тора. Ул елларда Республикакүләм уздырыла торган «Балкыш» ветераннар фестивалендә берничә ел рәттән лауреат исеменә лаек булалар.

2015 елдан «Садә» ансамблен мин җитәклим. Ансамблебез җыр белән генә түгел, ә фольклор юнәлеш алып, җирле материалларга нигезләнеп язылган «Бакырчы бакырлары», «Корама юрган бәхет китерсен», «Ахирәт сандыгы», «Йон эшкәртеп оекбаш бәйләү», «Бәби мунчасы» кебек театраль күренешләр белән Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге оештырган «Иске Казан Түгәрәк уен» фестивалендә берничә ел рәттән I дәрәҗә лауреат дипломнарына лаек булды. Республикакүләм уздырылган «Йортыбыз – Татарстан», «Балкыш», «Түгәрәк уен», «Уйна, гармун!» кебек бәйгеләрнең дә берсен дә калдырганыбыз юк. «Иске Казан түгәрәк уены»нда бик күп тапкырлар җиңү яулаганга, Түбән Новгород өлкәсенең Городец шәһәрендә узган Бөтенроссия «Зеленые святки» исемле фольклор-этнограф фестиваленә бару бәхетенә ирештек. Бу фестивальдә Россия төбәкләреннән 34 коллектив катнашты. Ә без Татарстан Республикасыннан бердәнбер булып, республика һәм Апас районы данын яклап, «Бакырчы бакырлары» күренеше белән чыгыш ясадык. «Корама юрган бәхет китерсен» тамашасын Казан Кремле мәйданчыгында күрсәттек. Берничә ел рәттән Биектау районы Сабантуена «Түгәрәк уен»ның актив коллективы буларак, кунакка чакырылдык, анда да үз чыгышларыбызны күрсәтеп кайттык.

Апасыбызда узган бер генә чара да «Садә»ләрдән башка үтми. Районыбыз авылларына барып концертлар куеп кайтырга да өлгерәбез. Быел да бу эшебезне дәвам итәбез. Бүгенгесе көндә ансамблебездә унбиш хатын-кыз һәм ике ир-ат гармунчыбыз бар.

«Садә»ләрнең чыгышын караган авыл тамашачысы ахырдан, күптәнге дусларын күргәндәй, шатланып рәхмәт сүзләрен ирештерәләр. Репетицияләргә җыелу үзе бер бәйрәм. Мәдәният йортын бер гөрләтеп алгач, урам буйлап гармунга җырлый-җырлый, «Апас таңнары» ресторанына чәй эчәргә кузгалабыз. Каршыбызга очраган райондашлар: «Күңелле яшисез, дәвам итегез, сезгә сокланмый мөмкин түгел», – дип минем апа-абыйларыма җылы теләкләрен юллыйлар.

2019 елда «Садә» ансамбленең 40 еллык иҗат эшчәнлегенә нәтиҗә ясадык, шул уңайдан зур чара – юбилей концерты оештырдык.

2022 елда безнең «Садә» фольклор ансамбленә халык исеме бирелде. Уңышларыбызны күреп, Татарстан Республикасының мәдәният министры Ирада Хафизҗан кызы Әюпова ансамбль әгъзаларына яңа күлмәкләр тектерде.

Быел февраль аенда ансамбльгә 46 яшь булды. Биш дистә елга якын вакыт эчендә ул шактый камилләште, яңа сулыш алды, бик күпләргә күңел күтәренкелеге өләште, яңа талантлар тупланды. Апасыбызның төрле өлкәләрендә хезмәт куйган, лаеклы ялда булган ханымнардан гына торган бу ансамбль – район Мәдәният йортының йөзек кашына әйләнде. Бирегә йөрүчеләрне «өлкәннәр» дип әйтеп тә булмый, алар искиткеч яшь күңеллеләр, чаялар, сүзгә тапкырлар. Мәңге шулай булып калсыннар иде!

**Земфира МӨХӘММӘТШИНА,**
**Апас Мәдәният йорты каршындагы**
**Апас халык театры һәм «Садә» халык**
**фольклор ансамбле җитәкчесе**

**Фоторәсемнәр авторның шәхси архивыннан**




**Татар халык әкиятләре = Татарские народные сказки = Tatar folk tales. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2024. – 215 б.**

# Камыр батыр

Борын-борын заманда, кәҗә команда, әби-бабай тумас борын, әти белән икәү генә торган чагында, бар иде бер карт белән карчык. Аларның балалары юк иде, шуңар кайгылары бик зур иде.

Бер заман болар исәпләделәр, уйладылар да камырдан бер бала сыны ясап куйдылар. Әби чыгып китте сыер саварга, бабай чыгып китте утын ярырга.

Керсәләр, исләре китте, акыллары таралды: камыр сыны, малай булып, кәҗә бәтиләре белән уйнап йөри.

Камыр малай төн үсә, көн үсә, ай үсәсен көн үсә, ел үсәсен ай үсә. Бабай ясап бирде, ди, моңа шартаяк. Малай бер таянган иде, ди, шартаяк шарт итеп сынды, ди. Бабай төшеп китте, ди, тимерчегә, ясатты, ди, моңа тимер шартаяк. Малай бер көнне урамга чыга – бер малайның аягын сындырып керә, икенче көнне чыга – икенче малайның муенын сындырып керә, ди.

Шуннан соң авыл халкы җыелып бабайга әйтәләр:

– Малаең малай төсле түгел, безнең балаларны имгәтеп бетерә, теләсәң кая куй! – диләр.

Чыгып китә малай дөнья гизәргә. Көн китә, атна китә, ай китә, ел китә, бер саплам җир китә. Барып керә, ди, бу бер карурманга. Очрый, ди, моңа аягын тышаулаган бер кеше.

Камыр батыр сорый моңардан:

– Нишләп тышауладың бу аягыңны? – ди.

Теге кеше әйтә:

– Миңа болай да таманга туры килә әле, – ди, – аягымны ычкындырсам, мин күккә очам, минем арттан кош-корт та куып җитә алмый, – ди.

Камыр батыр моны үзе белән ияртеп китә, ди.

Баралар-баралар, ди, бара торгач, очрый, ди, боларга борын тишеген бармагы белән кысып утырган бер кеше.

Камыр батыр сорый моңардан:

– Нишләп болай борын тишегеңне кысып утырасың? – ди.

Теге кеше әйтә:

– Миңа болай да таманга туры килә әле, – ди. – Югыйсә, дөньяда зилзилә куба, бер борын тишеге белән өрдереп тә биш ташлы тегермән әйләндерәм мин, – ди.

Камыр батыр моны да үзе белән ияртеп алып китә.

Баралар-баралар, ди, болар. Очрый, ди, боларга эшләпәсен кырын гына салган ак сакаллы бер бабай.

Камыр батыр сорый моңардан:

– Нишләп болай эшләпәңне кырын гына салдың? – ди.

Теге бабай әйтә:



Булат Гыйльванов рәсеме



**Булат Гыйльванов рәсеме**

– Миңа болай да таманга килә әле, – ди. – Мин эшләпәмне турыга кисәм, күз ачмаслык буран чыга, басып кисәм, җир йөзенә ике илле боз ката, – ди.

Камыр батыр монысын да үзе белән ияртеп китә, ди.

Баралар-баралар, ди, болар, очрый, ди, боларга ук төзәп торучы тагын бер кеше.

Камыр батыр сорый моңардан:

– Нәрсә атасың син болай? – ди.

Ук төзәп торучы әйтә:

– Ә-ә-ә-әнә күрәсеңме, теге тауның кабыргасында, моннан алтмыш чакрым җирдә бер чебен утыра. Шул чебеннең сул күзен атып чыгараем, – ди.

Камыр батыр моны да үзе белән ияртеп китә, ди.

Тагын китәләр, ди. Беравык баргач, очрый, ди, боларга туфрак белән уйнап торган сакаллы бер кеше.

Камыр батыр сорый моңардан:

– Нишләп болай уйныйсың? – ди.

Сакаллы кеше әйтә:

– Бу яктан сугам – бу якка тау өям, бу яктан сугам – бу якка тау өям, – ди.

Камыр батыр монысын да үзе белән ияртеп китә.

Барып җитәләр болар бер байга, сорыйлар моның кызын.

Бай бик кире була, төрле хәйләләр кора.

– Минем кызым бай кызы, патша кызыннан ким түгел, сиңдәйләргә тиң түгел, – ди. – Әйдә миннән булсын яхшылык, – ди, – йөгерешчемне узсаң, бирсәм бирермен инде, – ди.

Китәләр йөгерешкә. Аягын тышаулаган егет алтмыш чакрым җирне бер-ике сикерүдә барып җитә дә, бай йөгерешчесе килеп җиткәнче дип, тау өстендә йоклап китә.

Байның йөгерешчесе йөгереп мәйданга якынлашып килгәндә теге һаман йоклаган була, ди, әле.

Камыр батыр әйтә:

– Ай-һай, – ди, – бай малае җиңә бит, – ди. – Ат әле тегеңәр, – ди.

Алтмыш чакрымнан чебеннең сыңар күзен атып алучы кеше атып җибәрә, йөгерешченең колак яфрагын чеметтереп ала. Йөгерешче уянып китә дә мәйданга бай йөгерешчесеннән алда килеп җитә, ди.

Хәзер бай алай итә, болай итә, боларны алдап чуен мунчага яба, ди. Әрдәнә-әрдәнә утын өйдерә, ут төртә – боларны яндырып үтермәкче була. Болар мунча эчендә пешә башлыйлар, ди. Камыр батыр бабайның эшләпәсен туры кидерә – мунча эчендә күз ачмаслык буран кузгала, ди. Алай да пешә башлыйлар, ди. Камыр батыр бабайның эшләпәсен бастырып кидертә – мунча стенасына ике илле боз ката, ди.

Икенче көнне бай мунча ишеген ачып җибәрсә, шаккатып ботын чаба: болар барысы да исән!

Камыр батыр әйтә бу байга:

– Башымны катырма син минем, – ди. – Алыштанмы, салыштанмы? – ди.

– Алыштан да булыр, – ди, бай әйтә, – салыштан да булыр. Минем сиңа бирә торган кызым юк, көчең җитсә алырсың, – ди.

Китте алыш, китте егып салыш. Шундый алыштылар, шундый салыштылар – тигез җирләр түмгәк булды, түмгәк җирләр тигезләнде. Көн сугыштылар, төн сугыштылар, кич сугыштылар, бик озак сугыштылар. Бер борын тишеге белән өрдереп биш ташлы тегермән тарттыручы кеше борын тишеген сызгырттырып җибәрә – байның егерме кешесе очып китә. Туфрак белән уйнаучы бер яктан сугып җибәрә – утыз кеше күмелә, икенче яктан сугып җибәрә – утыз кеше күмелә. Камыр батыр күсәге белән бер селтәнә – утыз-кырык кеше кырылып бетә, ди.

Бай түзә алмаган, кызын бирергә булган, ди. Кызны Камыр батырга биргәннән соң, утыз көн уен итеп, кырык көн туен итеп, тумаган ала биянең итен пешереп, бик каты сыйланганнар, ди.

Туйларында мин дә булдым, аш-суның чиге юк, бәлешләренең төбе юк, мичкә-мичкә бал куйганнар, үзләре чүмеч белән чумыралар, миңа сабы белән генә эләкте.




# Кабак бәйрәме

**Рәйханә Степанова,**
*Кукмара, 7нче «Кыңгырау» балалар бакчасы тәрбиячесе*

**Катнашалар:**
Тәрбияче, Кабак, Акбай, барлык балалар да кабак булып киенәләр.

*Залның бер ягы яшелчә бакчасы итеп бизәлә, рәшәткә куела, чәчәкләр утыртыла.*

**Тәрбияче:**
Нинди матур көз килде,
Төрле төсләрне сипте.
Пумаласын тотып кулга,
Урман, басу, болыннарны,
Яшел чирәмлек, кырларны
Яратып сыйпап үтте.

*(«Көз килде» җыры башкарыла.)*

**1 бала:**
Кошлар китте җылы якка,
Саубуллашып җәй белән.
Каен яфраклары ява,
Димәк, җиргә көз килгән.

**2 бала:**
Көз килгән, көз! Күрегез,
Миләш, балан кызылдан.
Өрәңге яфраклары да
Инде җиргә коелган.

**Тәрбияче:** Әйе, балалар, бик ямьле дә, күңелле дә соң бу дөнья! Ямьле җәйләр артыннан кыш килми, ә алтын көз килә. Көз – бер караганда җылы, матур, икенче караганда, яңгырлы, суык булса да, алтын ул! Сары яфраклары өчен генә түгел, безнең барыбызга да кирәк булган икмәккә, яшелчәләргә, җимешләргә бай булганы өчен алтын ул.

**Тәрбияче:** Балалар, бүген без сезнең белән көз бәйрәменә җыелдык. Без аны сезгә таныш булган бик файдалы яшелчәгә багышларбыз, нинди яшелчә икәнен хәзер сез табышмаклар ярдәмендә белерсез.

Келәте бар, малы юк,
Баласының саны юк. *(Кабак)*

Үзе – бер бөртек,
Эче – мең бөртек.
*(Кабак)*





**Тәрбияче:** Бүген безнең балалар бакчасына бер конверт китерделәр. Эчендә нәрсә икән, әйдәгез, ачып карыйк әле, балалар.

*(«Шалкан» әкияте сурәтләнгән рәсем.)*

«Мин хәзер сезнең яныгызга килеп җитәм. Көтегез, сезнең Акбай!»

**Тәрбияче:** Балалар хатны кем язганын белдегезме? Бу рәсемдә кемнәр сурәтләнгән, кайсы әкияттән? Алар нишлиләр?

*(Машина тавышы. Акбай каплап нидер алып керә.)*

**Акбай:** Исәнмесез, балалар, менә сезгә бабайның бакчасыннан шундый зур яшелчә алып килдем.

**Тәрбияче:** Нинди яшелчә икән ул, балалар?

*(Балаларның җаваплары – кыяр, бәрәңге, суган, кишер...)*

**Акбай:** Ююк… Сездә бүген Кабак бәйрәме икәнен ишеткәч, бабам күчтәнәчкә кабак биреп җибәрде.

**Кабак:**
Карагыз әле бер генә,
Менә миңа – кабакка,
Турап куйсагыз мин сыймыйм,
Хәтта тугыз табакка.

**Тәрбияче:** Исәнме, Кабак! Сине үзебезнең бәйрәмдә күрергә без бик шат, безнең балалар синең хөрмәткә җырларлар, биерләр, төрле ярышларда катнашып, үзләренең зирәклекләрен, тапкырлыкларын күрсәтерләр.

**Кабак:** Рәхмәт, минем бер дә балалар бакчасында булганым юк, бик теләп сезнең бәйрәмдә кунак булыр идем.



**Тәрбияче:** Әйдәгез, балалар, Кабак белән якыннан танышыйк. Кабак нинди формада? *(Түгәрәк)*. Нинди төстә? *(Сары)*. Нинди зурлыкта? *(Зур)*. Аның кабыгы нинди? *(Калын, каты)*. Кабак кайда үсә? *(Бакчада)*.

**Тәрбияче:** Балалар, Кабакның үзенә генә күңелсез булмасын өчен аның дусларын – яшелчәләрне чакырыйк. Һәм алар белән бергә уйнап алыйк.

*(Балалар «Кәрзиндәге яшелчәләр» уенын уйныйлар – җиләк-җимешләр, яшелчәләр салынган кәрзиннән, яшелчәләрне аерып алып, исемен әйтеп, Кабакка тапшыралар.)*

**4 бала:**
Кояш та хәзер икенче,
Җәйге кебек җылытмый.
Яңгыры явып торса да,
Болар безне куркытмый.

**5 бала:**
Алтын көзне яратабыз,
Сагынып көтеп алабыз.
Көзге байлык, көзге икмәк,
Барсын җыеп алабыз.

**6 бала:**
Көз айлары бик күңелле,
Рәхәтләнеп уйныйбыз.
Матур бәйрәмнәр ясыйбыз,
Бергә-бергә җырлыйбыз.

**Кабак:** Булдырдыгыз, балалар! Сез көз турында бик күп шигырьләр, җырлар беләсез икән! Ә кабактан нәрсәләр пешерәләр, ясыйлар икәнен беләсезме?

*(Балаларның җаваплары – кабак бәлеше, кабак боткасы, кабак согы, кабак боламыгы...)*




**Акбай:** Әйе, балалар, бик дөрес, кабак ул витаминнарга бай яшелчә, аны пешереп тә, чи килеш тә ашыйлар. Аның төше дә бик файдалы.

**Акбай:** Мин сезгә табышмаклар алып килдем. Яшелчәләр, җиләк-җимешләр турында белемнәрегезне тикшереп карыйм әле.

Алсу битле кыз үсте,
Кызарып җиргә төште. *(Алма)*

Җир астында җиз бүкән,
Һәркөн ашыйсың, иркәм. *(Бәрәңге)*

Катлы-катлы тунлы, тәбәнәк кенә буйлы.
*(Кәбестә)*

Йодрык-йодрык булып үсә, алма кебек кызарып пешә, үзе бик матур, аны кем әйтер?
*(Помидор)*

Ул җир астына төшкән, кып-кызыл булып пешкән,
Ашка тәм һәм төс бирер, аны кем белер?
*(Чөгендер)*

Тураганда елата. Нәрсә ул? *(Суган)*
Тәрәзәсе юк, ишеге юк, эче тулы халык.
*(Кыяр)*

**Алып баручы:** Табышмаклар күп беләсез, зирәк икән үзегез! Әйдәгез әле, балалар, ял итеп, бер җырлап та алыйк.

*(«Матур бакча» җыры башкарыла.)*

**Кабак белән Эт:** Балалар сезнең бәйрәм бик күңелле булды, бик ошады, ләкин безгә әби белән бабай янына кайтырга кирәк. Бабайның бакчасында, кабак, шалкан гына түгел, әле бик тәмле алмалар да үсә, сезгә күчтәнәчкә бабай көзге алмалардан ясалган тәмле алма согы биреп җибәрде.

*(Кабак эченнән балаларга сок таратыла.)*

**Тәрбияче:** Бик зур рәхмәт сезгә! Сез килгәч, бәйрәмебез тагын да ямьләнеп китте, бабай белән әбиегезгә күчтәнәчләре өчен рәхмәтебезне җиткерегез. Сау булыгыз!

**Фоторәсемнәр авторның шәхси архивыннан**

# Бибиләр

*Наилә Яхина көе,*
*Ленар Шәех сүзләре*




*Хәтфә үлән йолкыйлар да,*
*Аргач, бергә йоклыйлар.*
*Суда да коеналар,*
*Туйганчы юыналар.*

***Кушымта:***
*Сары йомшак бибиләр,*
*Елмаеп: «Пи-пи», – диләр.*
*Йөгерәләр, уйныйлар,*
*Шаярышып туймыйлар.*
*«Пи-пи-пи-пи-пи-пи,*
*Пи-пи-пи-пи-пи,*
*Пи-пи-пи-пи-пи-пи», – диләр.*

*Каргалар оча, күзатып,*
*Бибиләрне күзәтеп.*
*Пумалам белән аларны,*
*Куып торам, кисәтеп!...*

***Кушымта: шул ук***

*Бибиләрне, уйнап туйгач,*
*Кертеп куям читлеккә.*
*Каргаларга мин берсен дә,*
*Бирмим инде, ничек тә!*

***Кушымта: шул ук***

# ТАТАР МИЛЛИ РИЗЫКЛАРЫ *турында табышмаклар*



- *Йомырка белән онны*
  *Бутап камыр басканнар.*
  *Бәрәңге, ит, тоз салып,*
  *Почмаклар ясаганнар.*
  *(Өчпочмак)*

- *Утырсам да мин менә*
  *Тыйнак кына, тик кенә.*
  *Эчем тулы ит кенә,*
  *Май белән, дөге белән.*
  *(Бәлеш)*

- *Тар авызлы, киң төпле.*
  *(Бәлеш)*

- *Зыр-зыр зырмани,*
  *Зырманида бормани,*
  *Борманида кәчтинкә,*
  *Кәчтинкәдә бәчтинкә,*
  *Авызы тар, төбе киң,*
  *Коерыксыз Хәснетдин.*
  *(Бәлеш)*

- *Чыж иттереп саласың,*
  *Бик тиз генә аласың.*
  *Балга манып кабасың,*
  *Ул нәрсә?*
  *(Коймак)*

- *Камыр эчендә бәрәңге,*
  *Йә, уйлап кара әле.*
  *(Кыстыбый)*

- Иттән генә торам мин
  Майга чумып чыгам мин.
  *(Пәрәмәч)*

- Табышмагым табы юк,
  Кашыгымның сабы юк.
  *(Пәрәмәч)*

- Вак-вак кына итеп кисеп,
  Өяләр аны таудай!
  Чак-чак кына алып өзеп,
  Аша дустым, син шулай.
  *(Чәк-чәк)*

- Үзе түгәрәк,
  Урыны түрдәрәк,
  Эче тулы күзәнәк
  Эчкелтем дә төчкелтем,
  Бар нәрсәдән дә кадерлерәк!
  Ул нәрсә?
  *(Ипи)*

- Сары куйлар суга батты,
  Шешенде дә өскә калыкты.
  *(Бавырсак)*

- Әгәри,
  Әгәри дә тәгәри,
  Тәгәри дә суга төшә,
  Күңелем шуны ярата.
  *(Токмач)*

- Минем ялгызымны ашамыйлар,
  Әмма миннән башка татарга аш булмый.
  *(Токмач)*

**Рәсем «Татарские пословицы» (Казань: Татар. книж. изд., 1979) китабыннан алынды. Рәссам В. Малякин**

**(«Татарханә» проектының презентация материаллары җыентыгы ТАТАРХАНӘ / ТАТАРХАНЕ / TATARHANE. Казан, 2022)**



# ВАК БӘЛЕШ

«Татарханә» проектының «Татар табыны» рубрикасыннан. Мастер-классны «Тәмле булсын» рестораннар челтәре җитәкчесе, Татар ашлары һәм мәдәнияте Халыкара ассоциациясе президенты, Татарстан Республикасының атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре, танылган аш-су остасы **Резидә Кыям кызы ХӨСӘЕНОВА** алып бара

## КИРӘКЛЕ ИНГРЕДИЕНТЛАР:

***Ачы камыр өчен:***

*300-400 миллилитр сөт,*
*30 грамм коры чүпрә,*
*2 данә йомырка,*
*0,5 чәй кашыгы тоз,*
*350 грамм атланмай,*
*1 килограмм он.*

***Эчлек өчен:***

*800 грамм сыер ите,*
*1 килограмм бәрәңге,*
*3 данә суган,*
*3 данә бадымҗан,*
*2 данә кишер,*
*тәменчә кара борыч, тоз.*



1 *Вак бәлеш өчен кирәкле булган ингредиентларны кушып, камыр басабыз.*



2 *Камыр кабарган арада эчлек әзерлибез. Аның өчен итне, бәрәңгене, суганны, кишерне, бадымҗанны шакмаклап турыйбыз. Тәменчә тоз, борыч кушып, барысын бергә болгатабыз.*



3 *Әзер камырны 100 граммлы вак кисәкләргә бүлгәләп, түгәрәк җәймәләр җәябез.*



4 *Әзер җәймәләрне тирән тәлинкә өстенә куеп, эченә эчлекне тутырабыз.*



5 *Өстенә камырдан капкач ясап каплыйбыз, кырыйларын бизәкләп бөреп, йомырканың сарысы белән майлыйбыз.*



6 *Әзер вак бәлешләрне табага тезеп, 180 градуска кадәр җылытылган духовкада 40-50 минут пешерәбез. Пешкән вак бәлешләрне алып, эретелгән атланмай белән майлап, чәй табынына чыгарабыз.*
***Ашларыгыз тәмле булсын!***

**Резидә Хөсәенова рецепты.**

**Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан**

# Бергәләп бизибез!



# Истәлекле даталар
2025

## ОКТЯБРЬ

**9 октябрь**

Композитор, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Илдус Дәүләт улы Якуповның тууына 90 ел (1935–2021)

**20 октябрь**

Татарстан Республикасы Дәүләт симфоник оркестрының сәнгать җитәкчесе һәм баш дирижёры, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының халык артисты Александр Витальевич Сладсковскийга 60 яшь (1965)

**21 октябрь**

Рәссам, педагог Ирина Никаноровна Хөсәинovaга 60 яшь (1965)

**23 октябрь**

Рәссам Дания Шамил кызы Шәймәрдановага 75 яшь (1950)

**29 октябрь**

Композитор, җырчы һәм музыка эшлеклесе, Башкортстан АССРның халык артисты Газиз Салих улы Әлмөхәммәтовның тууына 130 ел (1895–1938)

## НОЯБРЬ

**4 ноябрь**

Балет солисты, педагог-репетитор, күп кенә Халыкара конкурслар лауреаты, Казахстанның, Татарстан Республикасының халык артисты Бәхетҗан Смагуловка 60 яшь (1965). 1994–2008 елларда М. Җәлил исемендәге Татар опера һәм балет театры солисты. Бер үк вакытта шушы театрның педагог-репетиторы

**14 ноябрь**

Актёр һәм педагог, ТАССРның атказанган артисты, М. Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты Шамил Мәсгуть улы Бариевның тууына 75 ел (1950–1994)

**27 ноябрь**

ТАССРның атказанган артисты (Минзәлә театры) Мөслимә Гарифулла кызы Гарифуллинага 100 яшь (1925)

**27 ноябрь**

Рәссам, монументаль сәнгать рәссамы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының халык рәссамы, Россия Федерациясенең атказанган рәссамы Владимир Яковлевич Акимовка 75 яшь (1950)

**28 ноябрь**

Рәссам, П.П. Чистяков исемендәге Россия сәнгать академиясе премиясе лауреаты Рөстәм Фаит улы Хуҗинга 50 яшь (1975)

**30 ноябрь**

Актёр, ТАССРның халык артисты Һидаят Һидиатулла улы Солтановның тууына 110 ел (1915–2009)

## ДЕКАБРЬ

**3 декабрь**

Композитор, дирижёр, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, ТАССРның халык артисты Салих Җамалетдин улы Сәйдәшевнең тууына 125 ел (1900–1954)

**4 декабрь**

Актёр, режиссёр, Башкортстан АССРның халык, РСФСРның атказанган артисты Вәлиулла Гайназар улы Мортазин-Иманскийның тууына 140 ел (1885–1938)

**5 декабрь**

Педагог, шагыйрь һәм фольклорчы Сәхаветдин Кәшшафетдин улы Миңлекәйнең (Миңлекәев) тууына 130 ел (1895–1954)

**9 декабрь**

Шагыйрь, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Хәсән Фәхри улы Туфанның тууына 125 ел (1900–1981)

**14 декабрь**

Актриса, РСФСРның атказанган артисты Сара Нәбиулла кызы Байкинаның тууына 130 ел (1895–1972)

**17 декабрь**

Фольклорчы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Ленар Шәйхи улы Җамалетдиновка 90 яшь (1935)

**17 декабрь**

Архитектор, архитектура докторы, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе Нияз Хаҗи улы Халитовның тууына 75 ел (1950–2017)

**19 декабрь**

Журналист, публицист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Эльмира Мизхәт кызы Закировага 70 яшь (1955)

**21 декабрь**

ТАССРның атказанган артисты Бәһия Вәли кызы Вәлиеваның (Минзәлә театры) тууына 110 ел (1915–2002)

**25 декабрь**

Артист Ситдыйк Хәнәфи улы Айдаровның тууына 130 ел (1895–1938)

**https://kitaphane.tatarstan.ru сайтыннан алынды**





**Кадерле укучыларыбыз!**
2026 елның беренче яртыеллыгы өчен «Түгәрәк уен» альманахына республикабызның барлык элемтә бүлекләрендә, яисә «Почта России» сайты аша (https://podpiska.pochta.ru Индекс ПА 183 яисә «Тугарак уен» дип җыярга) онлайн да язылырга мөмкин.

**Индексыбыз – ПА 183**
**Өч айга язылу бәясе – 294 сум 07 тиен**
**Ярты елга язылу бәясе – 588 сум 14 тиен**

БЕРГӘ БУЛЫЙК, ДУСЛАР!